ИРЛЕ-ХАТЫНЛЫ ГАЛИМОВЛАР:
«Үзебез үстергән помидорны мартка кадәр ашыйбыз»
> 2

АВЫЛ ИМАМЫ
«ВТ» укучыларының саладагы дин әһелләре турында язмалары
> 3

СУД ЗАЛЫННАН
Яшь парның аерым яшәве фаҗигагә юл ача
> 5

БЕРГӘ ҖЫЕЛГАНДА
Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә
> 6

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 66 (28839) | Шимбә | 14 май | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ЗАҺИДУЛЛИНАР:
«КӨТСЕН БЕЗНЕ БӘХЕТЛЕ КАРТЛЫК»

Үрнәк гаилә

Сабырлык, ярату һәм хөрмәт. Балтач районының Бөрбаш авылында яшәүче Заһидуллинар гаиләсенең нигезе менә шушы сыйфатлардан төзелгән. Шул нигезгә таянып, сөю-сәгадәтле 14 ел үтеп киткән. Лилия белән Рөстәмнең гаилә йомгагын бергәләп сүттек.

Сөйләшә башлауга, Лилия татар хатыннарына хас тыйнаклык күрсәтте. «Рөстәмнән матуррак әйтә алмам, Рөстәмнән сорамыйсызмы соң, Рөстәм бу сорауга җавап бирер иде», – дигән сүзләр ишеттек. Әһә, ир сүзен сүз итеп, ир хакын хаклап яши, димәк, әңгәмәдәшебез!

Лилия – Бөрбаш Сәрдегәне авылы кызы. Фельдшер һөнәрен үзләштергән. Һөнәре булачак ире белән таныштырган дип әйтергә тулы хокукыбыз бар.

– Мин Рөстәмнәр авылында фельдшер булып эшләдем. Медпунктта очрашкалый идек. Сөйләшеп киттек. Рөстәмнең әбисе еш чирләп торгач, аны карарга бара идем, – дип истәлекләрен барлады әңгәмәдәшебез.

Көрәшче егет (спорт остасы!), эчми-тартмый, тыйнак, йөзгә-биткә дә бер дигән. Рөстәм нәкъ шул сыйфатлары белән дә җәлеп итә Лилияне. Сер түгел инде: мондый егетләрне хәзер сирәк очратасың. Берничә айлап очрашып йөргәч, мәхәббәт дигәне дә кабына бит күңелләрендә. Туй үткәреп, төп йортка килен булып төшә Лилия. Бу вакыйгалардан соң 14 ел узган да киткән. Мәхәббәтнең өч җимеше – Галия, Булат, Сәйдәшләрен үстерәләр хәзер. Гаилә башлыгы район башкарма комитетының яшьләр һәм спорт бүлеген җитәкли. Заһидуллинар төрле конкурс-бәйгеләрдә дә актив катнаша. Исегездә булса, «Нечкәбил», «Ел гаиләсе» Бөтенроссия конкурсында җиңү яулаган үрнәк гаилә дә әле алар. «Тик тора белмибез», – ди үзләре дә.

Яшерен-батырын түгел: яшь гаиләләрнең барысы да әти-әни белән бер йортта яшәргә ашкынып тормый. Ә менә Заһидуллиннар моның бар ямен-тәмен белеп көн күрә. Алар барысы өчен дә гаилә күрке булып торган әти-әнисенә рәхмәтле. Бала тәрбиясендә дә, көнкүрештә дә төп булышчылар бит алар.

– Минем әнием дә төп йортта яшәгән. Без шул мохитне күреп үскән. Андый тормышка әзер идем, дисәм дә була. Безгә дә әти-әни белән яшәү уңайлы. Без кайтышка кайнар ризык бар, ашарга пешкән, балалар өйдә, тәртип. Иртән китеп, кич кайтабыз бит. Болай яшәгәндә балалар өчен дә җан тыныч, – ди Лилия. – Төп йортка килен булып төшкәч тә, иремнең гаиләсе мине яратып кабул итте. Аерым торганчы, болай яшәүгә ни җитә, дибез. Тормышыбыз шөкер итәрлек! Балаларга да әби-бабай тәрбиясе кирәк. Шәһәргә күченеп китү хыялы булмады безнең. Авыл тормышын яратабыз. Бакчада маташу, чәчәкләр, яшелчәләр үстерү ошый. Рөстәмебез дә – авыл җанлы кеше. Хуҗалыгыбыз ишле. Балаларыбыз да шунда кайнаша.

Балалар димәктән, кыз-улларына хезмәт тәрбиясен сеңдерергә тырыша Заһидуллинар. «Без – кырыс әти-әни, таләпләр куябыз. Әмма чамасын беләбез. Акыру-бакыру юк, бездән куркып калтырап та тормыйлар. Әмма «әтиеңә әйтәм» дигән сүзне беләләр. Малайлар бигрәк тә. Эшләп үсегез дип, үрнәк күрсәтеп тәрбиялибез. Төрле түгәрәкләргә йөртәбез. Спортка да нык басым ясыйбыз. Җыр-моңга гашыйклар, өчесе дә җырлый. Кул арасына керәләр, шунысына сөенәбез. Кызыбыз ашарга пешерергә ярата. Камыр ризыкларын аеруча. Әле аңа – 13 кенә яшь. Район күләмендә WorldSkills чемпионатында да катнашты», – дип сөйли Лилия.

Гаилә булгач, савыт-саба шалтырамый тормый, билгеле. Ә менә Заһидуллиннар бу яктан эшне бик тиз тота: үпкәләп, озак вакыт сүз дәшмичә йөргәннәре юк. «Әйткәләшсәк тә, бер сәгать узамы икән, без янә сөйләшеп китәбез. Талашып яшәп булмый», – ди әңгәмәдәшебез.

Лилия белән сөйләшкәндә, аның мөлаем, зәвыклы, чибәр булып калуына игътибар итәсең. Хатын-кыз шундый инде ул: «Сере нидә соң?» – дип кызыксынмый булдыра алмадык. Бәлки, Лилия көн саен фитнес залына йөридер? Йә булмаса өендә тренажер залы бардыр? Әллә диета тотамы?

Җавабы исә без көткәннән дә гадирәк булды аның.

– Минем шулай сакланып калуымда ирем Рөстәмемнең өлеше зур. Хатын бәхете – ирдән. Үзем тик тора белмим. Нәселдән дә киләдер ул, – диде Лилия. Бу җәһәттән яшь парларга киңәше дә бар әңгәмәдәшебезнең: – Өйләнешкәнче, бер-береңне өйрәнергә кирәк. Үлеп-бетеп, яратам дип кенә булмый шул. Сүз күтәрмичә, бер-берләренә үпкәләп, кайтып китәрлек булмасын. Кайберәүләр әти-әниләр белән дә килешә алмыйлар. Гаилә булып яшәгәндә читләргә күз салмыйча да яшәргә кирәк.

Сөйләшкән шәпкә, тату, бәхетле гаилә рецептын да сорамый кала алмыйбыз бит инде. Бәхетле картлык турында хыялларын да белештек:

– Балалар безнең үрнәкне күреп үсә, безне кабатлый бит. Аларның сау-сәламәт булуын телибез. Әйбәт кенә укып, пар канатлы булып, үз тормышларын көйләп яшәсеннәр иде. Алда безне бәхетле картлык көтсен. Алтын туйларга җитеп… Күп оныклы әби-бабай булу хыялы бар.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Көн кадагында

Кулдан алганга ышаныч чамалы

Бер ай элек даруханәләрдән кырып-себереп запаска дару җыйган кешеләр бүген аларны очсызрак бәядән сата да башлаган. Бу хакта журналистлар белән очрашуда Татарстан буенча Росздравнадзор идарәсе башлыгы Любовь Шәйхетдинова хәбәр итте. Белгеч кулдан дару сатып алганчы, йөз кат уйларга киңәш итә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Кулдан дару сатучыларны күзәтеп бетерү кыен. Күпләр аны интернет аша сата. Без бу физик затка берничек тә басым ясый алмыйбыз. Андый хокукыбыз юк. Шуңа күрә халыкка мөрәҗәгать итә генә алабыз. Кулдан дару сатып алыр алдыннан яхшылап уйлагыз. Алар дөрес сакланмаган булырга мөмкин. Аның яраклылык вакытын төзәтеп, үзгәртеп тә сата алалар. Шуңа күрә даруны даруханәдән сатып алырга кирәк», – ди белгеч.

Любовь Шәйхетдинова даруханәләрдә сыйфатсыз, шикле дарулар сатыла алмый, дип ышандыра.

– Сез даруханәдә берничек тә теркәлмәгән яки сыйфатсыз дару сатып ала алмыйсыз. Ул биргә берничә кат тикшерү узып, махсус QR-кодлар ярдәмендә генә кертелә. Ә менә даруларны кулдан сатып алсагыз, шикләнергә җирлек бар. Соңгы арада С гепатитын дәвалаганда кулланыла торган даруларны читтән кертеп, безнең ил территориясендә сатучылар күзәтелә башлады. Без алар өчен җавап бирә алмыйбыз. Ник дигәндә, ул дарулар бездә теркәлмәгән. Әгәр шундый очрак белән очрашырга туры килсә, кичекмәстән безгә хәбәр итегез. Хокук сакчылары белән бергә бу проблеманы бик тиз хәл итәчәкбез. Базарга мондый шикле дарулар килеп керү – гадәттән тыш хәл, – ди белгеч.

Узган ел белгечләр әйләнештән Россиядә теркәлмәгән 80 мең кап дару алган. Аны сатучыларга зур күләмдә штраф яный. Әйтик, узган ел чәч коелудан ярдәм итүче шикле дару саткан кешегә 70 мең сум штраф салганнар. Андыйларны җинаять җаваплылыгына да тарта алалар.

Любовь Шәйхетдинова, бүген республикага дару кайтартуда тоткарлыклар юк, дип ышандыра. Бер ай элек даруханәләрдә күзәтелгән шаукым да тынган. Хәтерләсәгез, күптән түгел даруханәләрдә калкансыман биз авыруын дәвалаганда кулланыла торган «L-тероксин», вируслы авырулар вакытында кирәкле «Эргоферон» дарулары булмаудан зарландылар. Инсулин таба алмыйча йөрүчеләр дә шактый булды. Әмма бу проблема тиз арада хәл ителде.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

«Татар-информ» / В.Васильев

Айшат КАДЫЙРОВА, Чечен Республикасы мәдәният министры, республика башлыгы Рамзан Кадыйровның кызы:

Татарстанда милли традицияләргә, йола-гадәтләргә зур мәхәббәт белән карыйлар. Милли үзенчәлекләрне саклау өчен, монда иң алдынгы, заманча технологияләр кулланалар. Мин татар мәдәниятенә гашыйк булдым. Безгә үзара дус яшәргә язган икән.

(Социаль челтәрдәге шәхси фикере)

РОССИЯДӘ – ВАТАНПӘРВӘРЛЕК

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге белгечләре Россиядә яшәүчеләрдән: «Сез ватанпәрвәрме?» – дип сорашкан. Сораштыруда катнашучыларның 92 проценты үзен ватанпәрвәр дип атаган.

ГОРУРЛЫК ХИСЕН НӘРСӘ УЯТА?

18%......Кырымның Россиягә кушылуы

8%........ил спортчылары

5%........чикләүләргә карамастан, илнең тышкы сәясәте

4%.......Сочида узган Олимпия Уеннары

РКБда яңа үзәк төзеләчәк

Республика клиник хастаханәсендә югары технологияле медицина үзәге барлыкка киләчәк. Бу хакта сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков белдерде. Яңа бинада органнарны күчереп утырту һәм катлаулы башка операцияләр ясау өчен бөтен шартлар тудыру күздә тотыла. Үзәк бинасын проектлау турында карарны Президент Рөстәм Миңнеханов 12 майда – Халыкара шәфкать туташлары көнендә кабул итте.

Эшсезләр арткан

Апрель аенда республикада эшсезлек күрсәткече 0,54 процент тәшкил иткән. Татарстан Президенты матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, бу чорда рәсми рәвештә 10895 кеше эшсез дип танылган. Алдагы айда эшсезләр саны күп булган районнар исемлегенә Теләче (0,92%), Питрәч (0,76%) һәм Югары Ослан (0,70%) кергән. Мондыйлар сафына шулай ук Әлмәт (0,69%), Нурлат (0,65%), Саба (0,63%), Түбән Кама (0,62%), Алабуга (0,61%), Биектау (0,58%) районнары һәм Казан (0,65%) эләккән. Шул ук вакытта Балык Бистәсе, Апас һәм Ютазы районнарының эшсезлек буенча иң түбән күрсәткечкә ия булулары ачыкланган.

6 майга китерелгән мәгълүматлар буенча, Татарстанда теркәлгән эшсезләр саны бераз арткан:10948 кеше.

Ялган акча әйләнештә

Быел өч айда Татарстан банкларына 159 ялган акча килеп кергән. Шуның 131е – 5000 сумлыклар. Безнең акчадан тыш, 100 долларлык – 3, 50 долларлык – 1 һәм 20 долларлык 1 банкнотның ялган булуы ачыкланган.

Россия акчасының чынлыгын махсус җиһаздан башка гына: яктылыкка куеп, бармак белән капшап һәм бер почмагын өскәрәк күтәреп тә белергә мөмкин. Әйтик, яктыга куеп караганда, 1997 елгы үрнәктәге 5000 сумлыкның кырыйларында 5000 саны һәм Муравьев-Амурский портреты рәвешендәге су билгеләре күренә. Шулай ук биш меңлекнең алгы өлешендә, бер почмагын өскәрәк күтәрсәк, куе кызылдан алтынсу-зәңгәрсу төскә керүче Хабаровск гербы сурәтен күрергә була.

Моннан тыш Россия банкнотларында саклагыч җеп бар. Бишмеңлектә җепнең биш өлеше акчаның кире ягына чыга. Яктыга куеп караганда, саклагыч җеп кара төстәге тасма рәвешенә керә һәм анда 5000 саны барлыкка килә.

Яшенле һәм яңгырлы яллар

Татарстан Гидрометеоүзәгеннән хәбәр ителгәнчә, республикада яңгырлы, көчле җилле һава торышы урнашты. Ял көнне дә шундый ук һава саклана. Бүген көндез температура +20 градуска җитсә, төнлә +5…+10 градус булачак. Якшәмбе – 15 майда барлык районнарда диярлек яңгыр көтелә. Урыны белән яшен, секундына 15–18 метр тизлектә көчле җил. Көндез термометрның терекөмеш баганасы +14…+19 градус чикләрендә тирбәләчәк, ә төнлә +5…+10 градус күрсәтәчәк.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Койрык этне болгаса...

Гомере тулар-тулмас 8–10 мең ел булган кешелекнең Җир шарындагы беренче цивилизация түгеллеге хакында ныклы фараз яши галимнәр арасында. Бездән алда яшәгән, безгә иш һәм тартым, үзен акыллыга санап та, чынлыкта «сигезле-тугызлы» җәмгыятьләр, имештер ки, сансызлыклары, гармониядә яши белмәүләре, агрессивлыклары аркасында эзсез юкка чыккан. Әйе шул, алар да, бәлки, нәфес коллары булгандыр. Бәлки алар да, рухият ике аягына да аксаган тәкъдирдә, технологияләр дип ашкынгандыр. Даими сугышып, талашып яшәгәннәрдер. Шул хәл башларына җиткәндер. Әлеге җәһәттән алар баскан тырмага без дә басарга әзерләнмибезме, дигән сорау туа…

Бүгенге дөнья ул – барыннан да бигрәк капитализм. Ул – Яңа тарих дип аталган, соңгы биш-алты гасырны сыйдырган вакыт. Европада Яңарыш чорында ук старт алып, беренче буржуаз инкыйлаблар вакытында ныгыган, соңгы йөз елда техник яктан галәмәт алга киткән яшәү, тормыш итү калыбы. Аның төп үзлеге – бөтен гамәлләрнең дә табышка, акча артыннан чабуга һәм әйбер, мал-мөлкәт җыюга юнәлтелгән булуы. Ягъни бүгенге дөньябыз башыннан аягына кадәр материалистик. Ул уңайлыкларга, комфортка мөкиббән, ул артык мин-минлекле. Шуңа да анда рухияткә, иплелеккә урын шактый аз билгеләнгән. Бу – кеше дигән кавемнең бәласе. Шулай да Европада яралган капитализм кыйтганың үзен үстереп, баетып кына калмады, ул стандартлар, кыйммәтләр, ул яшәү рәвеше дөньяның бар тарафларына да таралды. Ул күренешне евроцентрализм – калган дөньяның да, зурдан алганда, шул стандартларга, аларча тормыш коруга омтылуы һәм коруы, дип атыйлар.

Яхшымы бу, начармы? Яхшы да, начар да. Яңарыш чорының антик заман ирекләрен, андагы беренчел чиста демократияне кире кайтарып, Европаны Урта гасырлар караңгылыгыннан чыгаруы яхшы гына түгел, хәтта ки бөек вакыйга. Тик аннан соң килгән чорларның ирек, либерализмны кирәгеннән артык киңәйтеп, бәндәнең комсызлыгын, аның мин-минлеген беренче урынга чыгаруы, материализмны абсолют дәрәҗәгә җиткерүе, әлбәттә, начар. Ни дисәң дә, рухи үсеш нәкъ менә шул чорларда – демократия ярларын югалткан заманнарда ныклап артка кала башлый да инде.

Биредә парадокс та бар: ирек арту тормыш сыйфаты яхшыру белән янәшә барган һәм бара. Бәс шулай икән, ничек инде ирекккә, ренессанс чоры даһилары уйлап тапкан принципларга ымсынмый калу кирәк?! «Тамак тук та, иман ник соң юк?» дип төпченүче, фәлсәфә куертучылар, ихтимал, булмагандыр да. Җиргә санаулы елларга гына килгән кешенең тук буласы килүен гаепләү дөрес тә түгел. Тик туклыкта да чикләр була. Икешәр, өчәр машина, берничә фатир, ел саен яңа айфон – болар инде туклыктан бигрәк майга чыдаша алмау. Тамак ач булып та, рухиятле, динле җәмгыятьтә гомер сөрү – монысы икенче чик. Андый чакларда алтын урталыкны таба белү зарур да бит. Ләкин кем эзли дә кем таба соң әле аны.

Тарихка карасак, борынгы Кытай, Һиндстан культураларында, язуларынча, матди як кеше тормышында күп дигәндә 20–30 процент урын алып торган. Мисырда тагын да азрак. Бәндәләр меңәр ел буе әйбер җыюны максат итмичә, рухи якны өстен күреп яшәгән. Европа кыйммәтләренә табынган бүгенге кешелек исә, ул илләрне дә кертеп, 80–90 процентка материалистик. Материализм тудырган күмәк культураның (аны квазикультура дип тә атыйлар), зурдан алганда, рухияткә бер катнашы да юк. Эш шуңа барып җитте, рухият дозасын, аның кирәкме, түгелме икәнен табыш артыннан куучылар, әйбер коллары билгели. Ә бит барысы да киресенчә булырга – байлык, табыш, без җыйган мал күләмен рухият, аңа ияргән югары әхлак билгеләргә тиеш. Алай булмау этнең койрыкны түгел, ә койрыкның этне болгавы кебек сәерлек. Ул – кешелекнең янә дә бер олы бәласе.

Бер караганда Европа, андагы күпчелек илләрдәге бүгенге тормыш – җирдәге оҗмах. Туклык, рәхәтлек, ирек, мөмкинлекләр. Яшә дә яшә. Ләкин рухияттәге сайлыкта – кешенең үзен дөнья кендеге, җиһан хуҗасы, җиргә бары рәхәтлекләр алып калырга килгән зат итеп күрүендә яхшылык аз. Капитализм исән булганда, барысы да шулай калачак. Кайчандыр Маркс әйткән «Яхшы табыш дигәндә капитал теләсә нинди җинаятькә әзер», дигән постулат та актуаль әле. Димәк, умыру, күсе кебек бар нәрсәне ояга ташу дәвам итәчәк. Инстинктлар исән, алар эшли. Ә бу хәлләр үз чиратында иманны, әхлакны, рухиятне бездән читтә тота, бәндәне затсызлыкта калдыра. Гаилә институтына кизәнүләр, табигать белән санлашмау – аннан барысын алып та, берни дә бирмәүдән башлап, геосәяси низагларга, ресурслар өчен тарткалашларга, сугышларга кадәр – һәммәсе шул чылбырның буыннары. Гомумән дә Җирдә, кешеләр арасында нинди әшәкелек бар – алар барысы да рухсызлыктан, кешенең кеше булып җитә алмавыннан. Техноген чордагы рухиятсезлек үзең утырган ботакка үзең балта чабуга тиң.

Кешенең Алланың кашка тәкәсе түгеллеген, аның чиксез галәмдәге кечкенә шарчыкны – Җирне үз иткән, шунда яралган биологик төр генә икәнен ассызыклыйсы килә. Кеше үз урынын, миссиясен белергә, бүгенге белән генә яшәмәскә тиеш. Үз ишләре, үзен юктан бар иткән табигать белән гармониядә яшәгәндә генә ул исән кала ала. Ә аның өчен һаман да шул рухи кыйммәтләр өстенлеге, алар тудырган тыюлар системасы кирәк. Һич югы рухият белән технологик революция арасында билгеле бер баланс булу кирәк. Башкача… Җирне, аның ресурсларын рәхимсез файдаланган комсыз һәм сансыз биологик төр планетаны хастага сабыштырып, соңгы йөз, йөз илле елда аңа тирән җәрәхәтләр ясый, шешләр тудыра. Акылыбызга килмибез икән, шешләр якын арада яманга әвереләчәк, метастазлар бирәчәк, үз кадерен үзе белмәгәннәрнең барысын да җәһәннәмгә аткарачак…

Капитализм дигәннән. Аны күпләр каһәрли. Тик аңа алмашка нәрсә, нинди формация килергә тиеш – берсе дә әйтә алмый. Миңа калса, капитализмга бары тик адәм чырайлы капитализм гына алмаш була ала. Аны кайдан алырга, дисезме? Ул бар инде. Ул – Төньяк Европа илләрендәге социалистик капитализм. Байларга күләмле прогрессив салым, мохтаҗларга – саллыдан да саллы социаль яклаулар. Геосәясәткә якын килмәү, тыныч яшәү, табигать белән санлашу. Рухият, иман, әхлак өлкәсендә дә креативлык күрсәткәндә, алар бөтен кешелеккә үрнәк яшәеш тудыра алыр иде.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

Төбәкләрдә онкологик ярдәм күрсәтүне алга таба үстерү һәм камилләштерү, «Онкологик авырулар белән көрәш» төбәк проектын гамәлгә ашыру. Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының Радиология илкүләм медицина тикшеренү үзәге генераль директоры Андрей Каприн һәм Илкүләм терапия һәм профилактика медицинасы медицина тикшеренүе үзәге директоры Оксана Драпкина Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов белән очрашуда шул хакта сөйләштеләр. Очрашуда профессиональ ассоциацияләр һәм җәмгыятьләргә сәламәтлек саклау юнәлешендә хезмәттәшлек итәргә булышу турында да сүз булды. Ачыклык кертәбез: Илкүләм медицина тикшеренү үзәкләре җитәкчеләре, 12–14 май көннәрендә Казанда узган Идел буе онкология форумы эшендә катнашу өчен, башкалага җыелды.

Кичә Рөстәм Миңнеханов Россия мәгариф һәм фән министры урынбасары Андрей Омельчук белән дә очрашты. Анда мәгариф өлкәсендә хезмәттәшлек итү, фәнни эшчәнлектә кайбер юнәлешләрне үстерү мәсьәләләре каралды.

tatarstan.ru

Бер-беребезне саклыйк!

15 майда иң якты һәм җылы бәйрәмнәрнең берсе – Халыкара гаилә көне билгеләп үтелә. Татарстанда яшәүчеләрне бәйрәм уңаеннан Татарстан Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева котлады.

«Безнең бөтен тормыш якыннарыбыз һәм сөеклеләребезнең яратуы, кадер-хөрмәте, игелеге белән сугарылган, – диелә котлауда. – Алар безнең шатлыклы, шулай ук сагышлы мизгелләрне уртаклаша, җиңүләргә илһамландыра, иң авыр чакларда күңелләрдә өметышаныч уята.

Гаилә – халыкның традицияләрен, мәдәниятен саклау, илнең бәһаләп бетергесез рухи-әхлакый мирасын саклау нигезе ул.

Күпмилләтле, күпконфессияле республикабызның һәм Россия Федерациясенең көче – гаиләдә, аның гармонияле үсешендә, киләчәккә ышанычыбызда!

Бу искиткеч матур көндә зур гаилә бәхете, иминлек, үзара аңлашып яшәү телим!

Бер-берегезне саклагыз!»

БЕРГӘ ТОТЫНГАН ЭШ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Мәрхәмәт

Тиздән авыл җирендә яшәп, өченче баласын алып кайткан хатын-кызларга акча урынына йә торак, йә машина бирергә мөмкиннәр. Моңа кадәр Татарстанда авылда яшәүче 29 яшенә кадәр 3 бала тапкан ханымнарга дәүләт акчалата ярдәм күрсәтә иде. Озакламый яшь чикләвен бетермәкчеләр. Идел буе округы хатын-кыз депутатлары шул хакта сөйләшкән.

Татарстан Дәүләт Советының хатын-кыз депутатларының «Мәрхәмәт» оешмасы җитәкчесе Алсу Нәбиева әйтүенчә, алар төрле төбәктә яшәүче депутат ханымнар белән очрашып, тәҗрибә уртаклашканнар. Очрашып сөйләшүнең максаты – һәр төбәктәге дәүләт ярдәмен өйрәнеп, үзара фикер алышып, безнең уңышлы программаларны – аларда, аларныкын Татарстанда эшләтеп җибәрү. Ике ай дәвамында алты утырыш уздырганнар.

– Без «Бердәм Россия» партиясенең халык программалары буенча эшләдек. Бергәләп очрашып сөйләшү тәкъдимен башка төбәкләр бик теләп кабул итте. 13 төбәктән барлыгы 101 тәкъдим алдык. Һәрбер төбәк үзендә яшәүче өлкәннәр, балалы гаиләләр, авыруларның тормышын яхшырту уңаеннан төрле фикерләр җиткерде. Тәкъдимнәрнең иң күбе Самара, Түбән Новгород, Оренбург, Пенза өлкәләреннән килде, – ди Алсу Нәбиева.

Төбәкләрдән җыелган тәкъдимнәр белән хәзер Дәүләт Думасы депутатлары һәм сенаторлар танышачак. Төбәкләрдәге депутатлар исә күрше өлкәләрнең кайбер законнарын үзләрендә кулланмакчы. Депутат хатын-кызлар авыл хуҗалыгы проблемаларын, авыру балаларны дару белән тәэмин итү, икътисади кризистан чыгу юлларын, авыр хәлдә яшәүче гаиләләр өчен «социаль контракт» төзеп булуы хакында сөйләшкәннәр.

Алсу Нәбиева әйтүенчә, халыкның сәламәтлегенә кагылышлы сораулар, тәкъдимнәр дә күп булган. Депутат ханымнар искәртүенчә, бигрәк тә авыл җирендә яшәүчеләр арасында әле дә дарулар кытлыгы бар икән. Утырышларда участок хастаханәләрендә дарулар сату турында да сөйләшкәннәр. Шулай ук шикәр авыруы белән авыручылар өчен дә даруларны авыл ФАПларына кайтармакчылар.

Депутатлар табибларның тормышын да яхшыртмакчы. Бу күбрәк авыл җирендә эшләүче фельдшерларга кагыла. Аларга өстәмә түләү тәкъдиме бар.

Федерация Советының Социаль сәясәт комитеты әгъзасы Оксана Хлякина утырышка онлайн кушылды. Аның фикеренчә, эш бирүчеләр хезмәткәрләрнең сәламәтлеген кайгыртырга тиеш. Шулай ук авыл җирендә эшләүче медицина хезмәткәрләрен торак белән тәэмин итү кирәк, диде ул.

Барлык тәкъдимнәрнең әлегә иң кирәклеләре сайланачак. Ел ахырында тагын бер утырыш булачак.

– Мондый очрашулар кирәк. Без һәр төбәкнең проблемасын өйрәндек. Аларны чишү юлларын табарга тырыштык. Бергәләп эшләгәндә, эшнең нәтиҗәсе булмый калмас, – диде Алсу Нәбиева.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Кулдан алганга ышаныч чамалы

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Белгечләр, аерым төр даруларга кытлык барлыкка килүгә, нигездә, кешеләр үзләре үк гаепле дип белдерде. Ник дигәндә, күпләр Россиягә карата кертелгән чикләүләр аркасында даруханәләрдә дарулар бетүдән куркып, артыгы белән запаска дару җыя башлады. Белгечләр бу хәлләр янәдән кабатланмасын дип тырыша.

– Әлегә бу яктан бар да тәртиптә. Складларда элеккеге дару запаслары бар. Бу эшкә яңа чаралар да кушылып, ярты елдан соң да вазгыять уңай булыр дип өметләнәбез. Әлегә фаразлау кыенрак, – ди идарә башлыгы. Любовь Шәйхетдинова даруханәләрдә шаукым булдырмауның тагын бер юлын атый.

– Кешене тикшереп, диагноз куйгач, даруны рецепт белән язып бирүне кире кайтарыр чак. Юкса, бүген күпләр даруханәгә дару исеме язылган мөһерсез, гади бер кәгазь белән генә килә. Кешедән ишеткән буенча гына дару килеп алучылар да бар, – ди ул.

Республика даруханәләрендә сатылган даруларның сыйфаты да, бәясе дә идарә тарафыннан контрольдә тотыла. Соңгы өч айда Татарстанда дарулар 1,9 процентка кыйммәтләнгән. Билгеле булганча, бүген әйләнештә булган 3,8 мең даруның 808е генә – яшәү өчен мөһим булганнар. Росздравнадзор идарәсе яшәү өчен мөһим булган дару бәяләрен генә контрольдә тота. Бу төркемгә кермәгән препаратларга исә даруханә дә бәя өсти ала. Бер үк төрле даруның төрле даруханәдә төрле бәядән сатылуы шуның белән аңлатыла.

Ел башыннан идарә даруханәләрдән 349 дару үрнәген сайлап алып, тикшерү уздырган. Аның барышында 4 төрле препаратның таләпләргә туры килмәве ачыкланган. Алар сатудан алынган. «Коронавирус котырган чорда кулланылган кислород сыйфатын да тикшердек. Ул шулай ук дару санала. Без тикшергән 150 кислород үрнәгенең барысы да сыйфатлы дип табылды», – ди Любовь Шәйхетдинова. Моннан тыш идарә дарулар сату турында шикле игъланнар урнаштырылган 700ләп сайтны да юкка чыгарган.

Якын арада даруларны дистанцион рәвештә сату өлкәсендә үзгәрешләр булмагае. Төгәлрәк әйткәндә, якын киләчәктә рецепт буенча гына җибәрелә торган дарулар да дистанцион рәвештә сатыла башларга мөмкин. Әлегә рецепт буенча җибәрелми торган даруларны гына шул рәвешле сату рөхсәт ителә. Любовь Шәйхетдинова сүзләренә караганда, даруларны өйдән торып кына сатып алу эше коронавирус пәйда булган 2020 елның маенда популярлашкан. Быел бу хезмәттән барлыгы 2,1 мең кеше файдаланган.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

БАКЧАЧЫЛАР:

«ПОМИДОРНЫ МАРТКА КАДӘР АШЫЙБЫЗ»

Чирмешән районының Югары Чыгтай авылында яшәүче Рәмзия һәм Марат Галимовлар 2000 нче еллар башында әти-әниләре, бертуганнары белән бергә Үзбәкстаннан Татарстанга кайтып төпләнгәннәр. Марат абыйның төп нигезе шушы авылда булгач, Галимовлар – биредә, ә калган туганнары Казан тирәсендәге бистәләргә урнашкан.

Аңа кадәр гаилә башлыгы Ташкентта теплицада чәчәк үстерү белән шөгыльләнгән. Шуңа күрә кайтуга, монда да яраткан һәм кулы белгән эшенә тотынган. Бер ел чәчәк үстергән дә яшелчәгә күчкән.

– Ул елларда чәчәкләрне сату авыр иде, – ди Рәмзия ханым. – Шуңа күрә бер елдан соң кыяр-помидор үстерә башладык. Ә кышын суган утыртабыз. Аларны монда бик яхшы алалар.

Хәзер Галимовларның өч теплицалары бар. Берсендә – үсенте, икенчесендә – кыяр, өченчесендә помидор үсә.

– Суганны февральдә бетерәбез дә мартта кыяр утыртабыз. Октябрьдә икебез дә коронавирус белән авырып, хастаханәгә эләктек. Шул сәбәпле утын әзерли алмадык. Быел шуңа күрә беренче уңышны соңрак алачакбыз. Якынча 3–4 көннән соң сатарга чыгарырлык булачак. Башка елларны апрельдә кыяр ашый идек инде, – ди хуҗабикә.

Помидор үсентеләренең теплицага һәм урамга утыртыр өчен уңышлы булганнарын үстерәләр. Рәмзия Галимова әйтүенчә, шушы еллар эчендә үз клиентлары да барлыкка килгән.

– Кыяр, помидорны, үсентеләрне базарда сатам. Быел әлегә бәяләрен белмим. Безнекеләр файдалырак булса да, кибет бәясеннән кыйммәтрәккә куеп булмый, – ди ул.

Теплица – төшемле эш, ләкин тәҗрибәле бакчачылар әйтүенчә, табыш килгәнче бик күп хезмәт куярга һәм барысын да үз вакытында эшләп барырга кирәк. Уңыш күләменә һава торышының да йогынтысы зур.

– Кыяр төнлә генә үсә. Шуңа күрә төннең җылы булуы кирәк. Гомумән, яшелчә үстерүнең үзенчәлекләре күп инде ул. Сөйли китсәң, бер көн дә җитмәс, – дип елмая Марат абый. – Иң мөһиме шул: кыяр тиресле туфрак ярата. Бер килограмм уңыш алыр өчен күп көч куярга кирәк. Ул җирдән микроэлементлар, калий, кальций һәм азот күп ала. Шуңа күрә туфракны һәрвакыт тукландырып торырга кирәк. Моның өчен кибетләрдә минераль ашламалар күп. Аларны күпме бирергә кирәклеге дә капларында язылган була. Шунысын истә тоту мөһим: ашламаны артык бирүдән файда юк. Икенчедән, теплица шартларында авырулар елдан-ел арта. Бигрәк тә һава торышы әледән-әле үзгәреп торуның йогынтысы зур. Корткычлар да куркыныч. Ләкин без авыруларга һәм бөҗәкләргә каршы чараларны алдан әзерлибез һәм башкаларга да шуны киңәш итәбез.

Мул һәм сәламәт уңыш алырга кул астында булган ысуллар да яхшы булыша икән.

– Пәрәвезле талпанга (паутинный клещ) каршы суган кабыгын кулланырга мөмкин. Аны өч тәүлек суда төнәтеп, су белән кушып, үсенте өсләренә шуны сибәргә кирәк. Ләкин мин аның урынына профилактика максатыннан фитоферун дигән биологик препаратны файдаланырга киңәш итәм. Гомумән, теләсә нинди авыруга каршы чараларны алдан хәстәрләргә кирәк. Авыруны исә бары тик химия белән генә җиңеп була. Ә без аны куллану яклы түгел, чөнки үзебезнең дә, якыннарыбызның да, сатып алучыларыбызның да сәламәтлеге мөһимрәк, – ди гаилә башлыгы.

Ашламаны да күп вакыт үзләре ясарга тырыша икән. Анысы өчен сыер һәм тавык тизәкләрен файдаланалар.

– Тавык тизәген зур мичкәләрдә ачытабыз. Ул ун көн торырга тиеш. Бер чиләк тавык тизәге 100 литр су белән кушыла. Күбрәк китсә, бөтен тамыр системасын яндырып бетерергә мөмкин. Фитофторозга каршы үземә иң ошаган чара – аертылган (майсызландырылган) бер литр сөткә 9 литр су һәм 10 г йод кушып, атнага бер тапкыр үсенте өсләренә сиптерү. Бу – иң нәтиҗәле ысул. Егерме ел яшелчә үстереп, бер тапкыр да әлеге авыруны теплицага керткәнебез юк. Моны теплицада да, урамда да эшләргә була. Фитофтороз гадәттә бәрәңгедә чыга. Аннан помидорга күчә. Теплица шартларында ул аеруча тиз тарала. Әгәр вакытында чара күрмәсәгез, бөтен уңыш юкка чыгарга мөмкин, – дип киңәшләрен бирде Марат Галимов.

Ирле-хатынлы Галимовлар әйтүенчә, күпләр хәзер алсу помидорга өстенлек бирә. Ул ашар өчен тәмле, ләкин тозларга бармый.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Урамда үскән помидорларны саклау авыр. Теплица өчен чыгарылган сортлар исә мул уңыш бирә. Алар кышка яхшы саклана, тик бәясе кыйммәтрәк. Без үзебез мартка кадәр помидор ашыйбыз, – ди алар.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышлана

БЕЗНЕҢ АВЫЛ ИМАМЫ

Тормышыбызда дин тыелган, мәчетләрнең манаралары киселгән чорлар инде тарихта калды. Шөкер, хәзер авыл-шәһәрләрдә иман йортлары күп. Анда халык күңеленә игелек тулы иман нуры салучы белемле дин әһелләре дә байтак.

Бүген авылымның дини дөньясын Әнәс хәзрәттән башка күз алдына китерү дә читен. 2012 елдан бирле Бакырчы авылының мәчетендә имам-хатыйп вазыйфасын башкара ул. Үзенең сабыр гына сөйләме белән эчтәлекле вәгазьләре аша халыкны җәлеп итеп, ислам диненә карата олы мәхәббәт тәрбияли. Авылда уздырыла торган һәрбер чара аның хәер-фатихасы белән башланып китә. Армия сафларына китүче егетләребез дә аның саваплы догалары белән ерак юлларга кузгала. Әнәс Мәгъсүм улы авылда өлкәннәргә һәм яшь буынга дини тәрбия бирү буенча зур эшчәнлек алып бара. Остаз буларак, мәдрәсәдә олысына-кечесенә белем биреп, ышанычлы, белемле шәкертләр тәрбияли ул. Дин дәресләренә үз авылыбыздан гына түгел, ә күрше авыллардан да бик теләп йөриләр. Гарәпчә укырга, язарга, дин нигезләрен өйрәтә, Коръән уку серләренә төшендерә. Күңел сафлыгын рухи чисталык белән бәйләп, үз кыйблаңны югалтмауны, милли гореф-гадәтләрне саклау кирәклеген аңлап эшли. Бакырчы шәкертләре, Коръән сүрәләре укып, Казанда узган «Сөембикә энеләре һәм сеңелләре» бәйгесендә җиңүләр яулады. Башкаладагы «Ярдәм» мәчете белән тыгыз элемтәдә тора. Ел саен, мохтаҗларга ярдәм йөзеннән, мәчеткә яшелчә, корбан ите илтәләр.

Авылда эшмәкәр Бәхтияров Рафыйк абый һәм Әлфия апа төзегән «Суфия» мәчете, күпер төзелешендә оештыру эшләрен әйдәп баручы булды ул. Хәзерге көндә имамнардан җаваплылык та, зур активлык та сорала. Алар мәчеттәме, җәмәгать урыннарындамы – бөтен җирдә халыкны дини агарту эшләрен алып бара. Шулай ук мәчетнең финанс эшчәнлеге дә аларга йөкләнелгән. Имам башка дин кардәшләренә үрнәк булырга тиеш. Теләсә нинди дәрәҗәдәге кеше каршына чыгып сөйләр өчен, үзенең тирән белемле булуы зарур. Элекке яшәешне белеп, бүгенге заман сулышын да тоеп эшли белергә тиеш. Безнең Әнәс хәзрәтебез шундыйлардан.

Аның бабалары да имам булганнар. 1849 елдан Ибниәмин хәзрәт Халитов авылда имам булып торган. Ул 1863 елда ахун дәрәҗәсен алган. 1899 елдан аның улы Гаязетдин хәзрәт имам вазыйфасын башкарган. Аннан соң имамлык Гаязетдин хәзрәт улы Габделгазизгә күчкән. Ә Габделгазиз хәзрәт – Әнәс хәзрәтнең әнисе ягыннан бабасы. Әнәс хәзрәт үзе дә 2007–2011 елларда Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем алды. Димәк, имамыбызның осталыгы буыннар аша күчкән. Бакырчы элек-электән дини авыл булган. Хәтта чукындыру вакытында да өйләрдә азан тавышы тынмаган, намазлар укылган.

dumrt.ru

БЕЗНЕКЕ КЕБЕГЕ ЮКТЫР

Авылыбызда Суфия апа Бәхтиярова балалары саваплы гамәл башкарып, әниләре хөрмәтенә «Суфия» мәчете төзеттеләр. Көн дә азан тавышы яңгырап, намазга чакыруы авылның динле һәм киләчәге өметле икәнен күрсәтә. Биш вакыт намазны мәчетебездә укучы картлар бар, җомга көннәрендә кеше күп җыела.

Бакырчы мәчетендә Мәүлид бәйрәмнәре мәрхүм Юныс хәзрәт Әхмәтшин муллалык иткән еллардан бирле уздырыла. Бу чаралар, нигездә, халыктан җыелган сәдака акчасына үтә. Чөнки бездә халык Коръән ашларыннан соң сәдаканы өйләренә алып кайтмыйча, әҗер-савабы булсын дип, мәчеткә тапшыра. Дини бәйрәмнәр оештырудан тыш, бәлагә тарып, авыр хәлдә калган, авырган, мохтаҗ кешеләргә дә ярдәм күрсәтелә. Шулай ук авыл күләмендә башкарылучы эшләрдә дә мәчет матди яктан булыша.

Район һәм республика дәрәҗәсендә дини бәйгеләр уздыру һәм анда яшь буынны катнаштыруда актив эшчәнлек алып барыла. Соңгы елларда «Суфия» мәчетендә Мәүлид кичәләре, Коръән укучылар бәйгеләре зурлап уздырылды. Тирә-күрше авыллардан, республика районнарыннан гына түгел, чит өлкәләрдән катнашырга теләүче балалар килгән иде. Бу кичәләр бер-берebезгә карата ихтирамлык хисләрен арттырып кына калмый, ә үсеп килүче буынның иманлы, әхлаклы булуын ачык күрсәтә.

Әнәс хәзрәт ел да тыл ветераннарына, сугыш чоры балаларына бүләкләр тапшыруны оештыра. Балалар бакчасындагы, мәктәп яшендәге балаларны да бәйрәмнәрдә бүләксез калдырмый. Имамыбызның эш-гамәлләре, теләк-омтылышлары ата-бабаларыбызның, гомумән, халкыбызның бай мирасын саклауга һәм хөрмәт итүгә юнәлгән. Аның республикакүләм «Изге әманәт» бәйгесендә «Иң яхшы имам-хатыйп» номинациясендә 1 нче урынга лаек булуына һәркем сөенде.

Әнәс хәзрәт авылыбызда Чишмә янындагы паркны оештыруга да зур өлеш кертте. Чишмә буена юкә, каштан агачлары утыртылды, бик матур ял паркына әйләнде. Хатыны Рәшидә апа җитәкчелегендә бу урын гөлбакчага әверелде. Җәй буе аллы-гөлле чәчәкләргә күмелеп, авылымны бизәп торган урын ул хәзер. Шушы паркка куелган һәрбер экспонат авылымның тормышын, авылдашларымның хезмәтен күрсәтеп торучы ачык һавадагы музей сыман. Мөхтәрәм Әнәс хәзрәтнең үз куллары белән ясаган тегермәне – бабаларыбызның тегермәнле булып гел икмәкле яшәүләрен, кое макеты – авылыбызда тирә-якка данлыклы оста кое казучылар яшәгәнен мәңгеләштергән әйберләр. Томырылып барган поезды һәм күкләрне иңләргә әзер самолеты авылымның матур киләчәгенә, авылдашларымның данлыклы эшләренә ышаныч сыман ерактан балкып торалар. Әнәс хәзрәтнең тагын бер иҗади эше – карета. Ул шушы паркка ниндидер серле әкияти төсмер өстәп, үзенә чакырып тора. Шушы матурлыкны бәяләп, сакчыл караш булдыру – һәрберебезнең бурычы. Осталар күп, әмма эшен халык хозурына куярга теләүчеләр сирәк бит.

Авылыбыз имамы Әнәс хәзрәт кебек авылның өметле киләчәге өчен, олылар гына түгел, балалар да дини белемле булсыннар өчен тырышып, җан атып йөрүчеләр булганда, тормышыбызның имин булуына ышанычыбыз нык. Киләчәк тормышына иминлек һәм муллык теләп, имамыбызның сау-сәламәт булып, тирә-юньгә иман нуры таратып, озак яшәвен телибез.

Энҗе ИСМӘГЫЙЛОВА.
Яшел Үзән районы Бакырчы авылы

922
2022

Болгар 1100

1100 еллык тарих

Тарих фәннәре докторы, профессор Фаяз ХУҖИН ярдәме белән 1100 ел элек Идел Болгарстанында ислам дине кабул ителү уңаеннан тарихи язмалар циклын дәвам итәбез. Болгар шәһәрләрендә озак еллар казу эшләрен алып барган, ислам дине тарихын өйрәнүгә зур көч куйган галимгә шушы уңайдан сорауларыгызны да җиткерә аласыз.

Биләр

Багдад илчелегенең Болгар иленә килүенә бер ай чамасы вакыт үтеп тә китә. Җәгъфәр ибн-Абдаллаһның Багдад хәлифәсенә язылган һәм хәлифә тарафыннан ярдәм итәргә вәгъдә бирелгән тагын бер бик мөһим мәсьәләне хәл итәсе кала. Ул да булса – Болгар илен яһүдиләрдән, ягъни Хәзәр патшасыннан саклау өчен хәрби ныгытма – крепость һәм мәчет төзүгә бәйле эшләр. Билгеле булганча, бу вакытта болгарлар Хәзәр каһанлыгының вассаллары булып торалар. Җәгъфәр ибн-Абдаллаһның улы Итилдә тоткынлыкта газап чигә, сөекле кызын, җария итеп, хәрәмдәге хатыннар янына алып китмәкчеләр. Шуңа күрә, Болгар патшасының хәзәрләрдән бәйсезлеккә омтылуын аңларга була.

Крепость төзү мәсьәләсен Багдад илчеләре белән очрашуда Болгар ханы үзе күтәрә. Эш шунда: Багдад хәлифәсе үзенең хатында Болгар илендә ныгытылган кала төзү өчен, Аллаһы Тәгалә тарафыннан мөмкин дип саналган чыганаклардан алып, дүрт мең динар акча вәгъдә иткән була. Ибн Фадланга кагылмаган төрле сәбәпләр аркасында, бу акча Болгарга килеп җитми. Ахыр чиктә Багдад илчесе Болгар патшасыннан: «Синең дәүләтең бик зур, акчаларың күп, керемең күпсанлы, ә син ни өчен хәлифәдән киләчәк аз гына акчага ныгытма төзеп бирсен дип үтендең?» – дип сорый. Җәгъфәр ибн-Абдаллаһның җавабы бик төпле була: «Ул акча дини кануннар тарафыннан рөхсәт ителгән чыганаклардан алына дип санадым. Һәм, чыннан да, әгәр дә мин үземнең акчага, көмешләргә яки алтыннарга ныгытма төзергә теләгән булсам, минем өчен бернинди авырлык булмас иде».

Һәм Болгар ханы Җәгъфәр ибн-Абдаллаһ Җаушир (Кече Чирмешән) дип аталган елга янына кузгалып китә. Биредә ул ике ай чамасы була. Җауширгә киткәнче, барлык кабилә башлыкларына хәбәр җибәрә. Алар, үзләренә буйсынган халыкның бер өлешен (ир затларын) алып, килеп тә җитәләр. Арада сувар (суваз) дип аталучы кабилә юлбашчысы гына күренми. Алар, күрәсең, Җауширгә барудан баш тартканнар. Болгар патшасы аларга тагын бер чакыру җибәрә һәм кисәтә: «Кодрәтле һәм бөек Аллаһ миңа ислам динен һәм мөселманнар хөкемдарының хакимлеге дәрәҗәсен бүләк итте. Һәм мин аның колы, бу эшне Ул (Аллаһ) миңа үзе йөкләде... Һәм кем дә кем миңа каршылык күрсәтә, мин аны кылыч белән каршы алачакмын». Бу кисәтүдән соң сувар халкы тиз арада Болгар ханына кушыла.

922 елның җәендә Җаушир елгасы янында нинди вакыйга булган соң? Бу турыда Ибн Фадлан язмаларында бер сүз дә әйтелмәгән (хәер, ул язмалар безгә тулысы белән килеп тә җитмәгән). Галимнәр фикеренчә, Җаушир елгасы буенда Җәгъфәр ибн-Абдаллаһ белән килгән болгар төзүчеләре һәм Багдад илчелеге составына кергән шәһәр төзү осталары Биләр каласына нигез салалар. Эшне хәрби ныгытмалар һәм булачак шәһәр үзәгендә мәчет төзүдән башлыйлар.

Багдад илчелеге составында башта берничә мең кеше була. Алар арасында ислам дине белгечләре һәм хәрби ныгытмалар, шәһәр-крепостьлар төзү буенча тәҗрибәле осталар булгандыр дип уйларга кирәк. Илчелекнең бер өлеше, бәлки әле күпчелегедер дә, юл авырлыкларыннан куркып, кире кайтып китәләр. Ә Болгарга килеп җиткәннәре арасында, һичшиксез, шәһәр ныгытмалары һәм мәчетләр төзү осталары булгандыр. Бу турыда Шиһабетдин Мәрҗани дә яза.

Биләр бер-берсенә кереп утырган ике өлештән – бер үк вакыт аралыгында барлыкка килгән эчке һәм тышкы шәһәрләрдән тора. Урыны-урыны белән икешәр рәтле калын диварлар – туфрак өеп ясалган биек үрләр, шул үрләргә куелган агач буралар һәм башнялар белән ныгытылган эчке шәһәрнең мәйданы 130 гектар чамасы. Өч рәт диварлар белән уратып алынган тышкы шәһәр исә 490 гектар җирне биләп тора. Крепость диварларының гомуми озынлыгы 40 километр чамасы. Шунысы кызык: Биләр үзенең планы белән урта гасырлар Багдадына охшаган. Күрәсең, Биләргә нигез салуда катнашкан Багдад белгечләре, интуитив рәвештә булса да, үзләренең шәһәр образын күз алдында тотканнар.

Биләрнең эчке шәһәрендә, аның үзәгендә диярлек, XVIII–XIX йөз сәяхәтчеләре һәм төбәк тарихын өйрәнүчеләре борынгы мәчет урынын табып алалар. 1970 нче елларда Казан археологлары шул мәчет хәрабәләрен казып чыгардылар. X гасырның беренче яртысында ул ике өлештән торган. Борынгысы, 1400 квадрат метр мәйданда агач бүрәнәләрдән салынган өлеше, профессор Альфред Халиков фаразлавынча, IX гасырда ук корылмаган микән? 922 елда аның ак таштан салынган өлешен торгызганнар булса кирәк. Ул 1076 квадрат метр мәйданны били. Таш мәчетнең эчендә алты рәт колонналар тезелгән (һәр рәттә дүртәр колонна). Көньяк-көнчыгыш дивары ярымколонналар белән ныгытылган.

Бу – Идел Болгары дәүләтендә археологлар тарафыннан өйрәнелгән иң борынгы мәчет һәм ул, турыдан-туры булмаса да, Биләрнең беркайчан да гади шәһәрләр рәтендә йөрмәвенә ишарәли. Белгечләрнең раславынча, ул заманнарда Җәмигъ мәчете – вәгазь сөйләү һәм ил хакиме (хан/әмир) исемен кушып хөтбә уку өчен, имам-хатыйпка дип махсус ясалган мөнбәре белән – бары тик дәүләтнең административ үзәгендә генә булган.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА әзерләде



КАДЕРЛЕ ЕЛ

Татарстан Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен рәсми рәвештә кабул итүнең 1100 еллыгын билгеләп узарга әзерләнә. Бу уңайдан Россия ислам институты нинди чаралар уздырачак?

Билгеле булганча, 19 майда Казанда «Россия – ислам дөньясы: KazanSummit 2022» XIII халыкара икътисади саммит узачак. Россия ислам институты һәм Казан ислам университеты ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин сүзләренчә, әлеге чара кысасындагы Russia Halal Expo күргәзмәсендә институт мастер-классlar уздырачак. «Гомумән, Россия ислам институты каршындагы ислам икътисады үзәге саммит эшчәнлегендә актив катнаша. Әлеге үзәк Россия законнары белән бер рәттән ислам кагыйдәләренә туры килә торган күп кенә икътисади проектлар әзерләде», – диде ул. Әлеге проектлар арасында ислам ипотекасы, кыйммәтле кәгазьләргә хәләл инвестицияләр, ислам стандартларына туры китереп финанслау бар. Казан ислам университетының уку эше буенча проректоры Рөстәм Нургалиев сүзләренчә, бу проектлардан, нинди генә дин вәкиле булса да, һәркем файдалана ала.

Россия ислам институты 1100 еллык кысасында май ахырында ислам һәм гарәп теле буенча россиякүләм олимпиада уздырачак. «Бу олимпиада беренче мәртәбә генә уздырылмый. Институтыбызның тагын бер «фишка»сы ул», – диде ректор.

Шулай ук институт ел ахырына кадәр дүрт яңа җыентык чыгарырга ниятли. Әйтик, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре заказы белән алар «Россиядә ислам тарихы» дип исемләнгән китап чыгарырга әзерләнә. Әлеге китап өч телдә – рус, инглиз һәм гарәп телләрендә басылачак.

Планлаштырылган чаралар арасында көз көне үткәреләчәк мөселман белем бирү оешмалары мөгаллимнәренең россиякүләм форумы да бар. «Бу безнең өчен дә, гомумән, мөселман белем бирү системасы өчен дә мөһим чара булып тора», – диде Рәфыйк Мөхәммәтшин.

Россия ислам институты 1100 еллык уңаеннан фотоконкурс та игълан иткән. Әлеге бәйгедә 31 майга кадәр теләгән һәр кеше катнаша ала. Номинацияләре – «Минем гаилә тарихында милли традицияләр», «Туган як табигате», «Татарстан мәчетләре», «Россия мөселман халыкларының милли бәйрәмнәре». Җиңүчеләрне кыйммәтле бүләкләр көтә. Бәйге турында тулырак мәгълүматны ислам институтының рәсми сайтыннан табарга мөмкин.

Кылган эшләре белән матур

Туган авылым – Әлки районы Яңа Салман авылында мәчет 1993 елның 25 декабрендә тантаналы рәвештә ачылды. Авылыбыз мулласы Миңнегәрәй Хәйрулла улы Хәйруллин тантаналы чарада Аллаһ йортының ачкычын кабул итеп алды. 17 ел дәвамында имамыбызның башкарган изге эшләре бихисап булды. Бүген авылыбызның имам-хатыйбы вазыйфасын аның улы Марат башкара.

Әйтик, мәчетнең эчке диварлары тышланды, тәрәзәләр пластикка алыштырылды, мәчет тирәсенә тимер рәшәткәләр тотылды. Хәзер безнең ике зиратыбызның да бинасы бар. Бер зиратыбызның коймасы тулысынча яңага алыштырылды, мәчет янындагы бина төзекләндерелде. Саный китсәң, матур эш-гамәлләр бихисап.

Муллалар нәселеннән булган Марат хәзрәт мәхәллә кешеләрен мәчеткә өнди һәм шул рәвешле сафларыбызны ныгыта. Намаз укыганда имамыбызның төгәл һәм җитез хәрәкәтләренә сокланып карыйм. Аның кайгыртуы һәм даими тырышлыгы аркасында мәчетебез төзек һәм җылы, ике гаетебез дә матур вәгазьләр тыңлап үтә. Мин үзем дә чыгышлар ясыйм, динебезне алга сөрәм, күңелгә уңай тәэсир иткән якларын барлыйм, мисаллар китерәм. Үземне кызыксындырган сорауларга җавапны имамыбыздан алам, ул – минем өчен мөгаллим.

Авылыбыз имамы Марат хәзрәт изге эшендә булганда үзәктә урнашкан мәчеттән иман нуры сибелеп, намазга өндәп, моңлы азан тавышы ишетелеп торыр.

Фердинанд МӘХМҮТОВ

АНЫ САЙЛАП ЯЛГЫШМАДЫК

Илдар Мөхәммәтҗанов

2009 елның 12 сентябрендә туган авылым – Әтнә районы Яңа Җөлбидә мәчет ачуга багышланган җыелыш үткәрелде. Мин күрше авылда – Кече Әтнәдә яшим. Имам-хатыйп булып эшләгән вакыт. Җыелышны алып баруны миңа тапшырдылар. Мәчет ачу тантанасына чакырылган кунаклар да, авыл халкы да бик күп җыйналган иде. Авылыбызда 20 еллап мулла вазыйфасын башкарып йөргән бабай каты авырып, яңа мулла сайлавыбызны үтенеп хат язып җибәргән. Яңа ачылган иман йортына хуҗа, ачкычларын кабул итеп алучы, имамлыкка лаеклы кеше кирәк булды. Мәчет салдыруда башлап йөрүче Фәнис Бузунов, авылыбыз абыстае Фәтхия апамнар белән киңәшеп, бу эшне берничә ел элек пенсиягә чыккан Мәхмүт Шакировка тәкъдим иттек. Авыл халкы бу фикерне бертавыштан хуплап, яңа мулла, мәчетебезгә имам сайладык.

Без аның тыныч, сабыр, пакьлеккә омтылучы, үзен төрле хәрамнардан тыя белүче, намуслы, гадел, эш сөючән, мактанырга яратмаучы икәнен, дини хезмәтләрне башкарганда һәрвакытта да пакь, чиста киемнән булуын һәм күп кенә башка яхшы сыйфатларын яхшы беләбез. Ул беренче көннән үк халык ышанычын акларга тырышып, имам вазыйфасын намус белән башкарып килә. Белмәгәннәрен белгәннәрдән сорашып, дини китаплар укып, яхшы ук белемен күтәрде. Мәетләрне шәригатькә муафыйк итеп озатырга, никах укырга, исем кушарга, Коръәнне тәҗвид белән дөрес укырга, намаздагы рөкугъ һәм сәҗдәләрне дөрес итеп башкарырга авылыбызда туып-үскән, хәзерге вакытта Биектау районында дини хезмәттәге ир-егетебез ярдәм иткән. Мин үзем дә ике дистә ел имам-хатыйп булып эшләгән кеше, күп дини язмаларның авторы буларак, ярдәмемне күрсәтергә тырыштым. Мәчетебездә беренче гает намазын үземә үткәрергә насыйп булды. Иртәнге намазга азанны муллабыз үзе әйтте. Шул вакыттан башлап авылдашларны намаз гыйбадәте кылырга чакырып, биш мәртәбә азан әйтелә. Азанчының моңлы тавышы авылдашларыбызның күңелләрен назлый, еракларга яңгырап, җаннарга рәхәтлек, авылга иман нуры бирә. Авылыбыз кечерәеп калу сәбәпле, намазга йөрүчеләребез күп түгел. Әмма күршедә генә яшәүче Мәйсара әби, өлкән яшьтә булуына карамастан, бик теләп һәрбер намазда катнаша диярлек.

Диния нәзарәте шаһәдәтнамә биргәч, Мәхмүт хәзрәт, искечә әйтсәк, указлы мулла булды. Ул мәчетнең керемнәре һәм чыгымнары турында авыл халкы алдында ике гаетнең берсендә исәп-хисап тота. Бөек Ватан сугышында катнашучылар хөрмәтенә мәчет алдында һәйкәл булдырылды, кое казылды. Үткән-киткәннәргә су эчеп, ял итеп алу өчен урындыклар куелган. XVIII гасыр башыннан ук мәетләр күмелеп килгән каберстаныбыз кечкенә түгел, әйләнәсенең озынлыгы бер мең метрдан да күбрәк. Аны да һәр ел чистартып карап тору эшләрен оештыру элек-электән авыл мулласы җаваплыгында булган.

Хәзерге вакытта каберстанны яшел калай койма белән уратып алу эшләре төгәлләнеп килә. Бу саваплы зур эш тә мәчеттә тупланган сәдака акчасына, игелекле, иманлы ир-егетебез Фәнис әфәнде, Мәхмүт хәзрәт ярдәме белән башкарыла.

Мин имам-хатыйп булып эшләгәндә, районыбызда башкаларга караганда өстенрәк күргән биш мулла бар иде. Икесе инде бакыйлыкка күчте, җаннары җәннәтле булсын. Аллага шөкер, һичшиксез, авылыбыз мулласы да –шундыйларның берсе.

Әнелулла ГАЛӘВИЕВ.
Әтнә районы Әтнә авылы

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

Бер дә гаҗәпләнмәдем

Моннан берничә көн элек кенә интернет Казанда ишеп-ишеп яуган яңгыр турында мәгълүмат белән тулды. Хәтта чит илдә яшәп ятучы Собчак та ни сәбәптәндер активлык күрсәтте: Россиянең өченче башкаласы су астында, дигән хәбәр таратты. Чыннан да, Казаныбызның Вишневский, Зур Кызыл, Ершов урамнарында, үзәктә һәм башка урыннарда машиналар ташкыны яртылаш суга күмелгән иде, җәяүлеләрнең ни хәлдә калуын әйтеп-сөйләп кенә бетерерлек түгел. Мәхшәр инде! Минем үземә дә хәбәрләр яңгыр кебек үк ишелеп килде. «Син моңа ышанасыңмы?» – дигән сораулар да куелган иде. Ничек ышанмыйсың ди! Әмма мин бу «яңалык»ка һич гаҗәпләнмәдем.

Үземнең туган ягымда – Арча төбәгендәге Апаз авылында 1961 елда коеп-коеп, чиләкләп-чиләкләп яуган яңгыр хәтердә яңарды. Яңгыр төн буе койды, иртән инде авыл тулысынча су чолганышында иде. Авылдашларыбыз хафаланды, әти, һич югында тауга менеп котылырбыз дигән нияттәндер инде, тракторын алып кайтып, өй янәшәсенә куйды. Күрше-тирәдәгеләр йорт-җирләрен аслары җиргә яхшылап беркетелгән таш баганаларга бәйләп кую хәстәрен күрде. Ул да булмады, Наил Миннебаев исемле авылдашыбыз (без аны фотокорр дип йөртә идек), бүрәнәгә утырып, безнең тирәгә үк төшеп җиткән. Кулында – әлеге дә баягы фотоаппарат, төшерепме-төшерә.

Су кичкә таба кимеде, әмма бөтенләй үк агып бетмәде. Тәүлек ярым эчендә бәрәңге бакчалары, каз, тавык оялары, терлек абзарлары тулысынча су астында иде, күпләп кош-кортлар һәлак булды, эрерәк маллар да акты һәм алар, йөзеп, тау башына үрмәләде. Күршедәге Хәсәншәехтә авылдан биш-алты километр читкә аккан кинодвижокны алып кайтулары да хәтердә калган.

Язуымча, Казанны су басу мине әллә ни гаҗәпләндермәде. Тик шунысы гаҗәп бит әле: Кремль, цирк тирәләре су астында чагында, «Идел-пресс» яны, Мәскәү – Киров районнары урамнары коп-коры, аларга бер тамчы да төшмәгән иде. Табигать менә шундый могҗизаларга бай һәм шуның белән шаккатыра да инде. Әмма нинди генә очракта да төшенкелеккә бирелмәү мөһим. Хәвеф-хәтәрләрдән ничек саклануыбыз үзебездән тора.

«Апрель сулы икән, май үләнле булыр», – диелә халык сынамышларында. Метеокүзәтүчеләр апрель аенда явым-төшемнең нормадан күпкә артык булуын, гомумән, кышын карның мулдан явуын хәбәр итте. Игенче файдасына бу, өстәвенә салкын көннәр җылы белән аралашып тора. Авыл хуҗалыгы тармагы өчен ел уңышлы килә. Бу инде – терлекчелекнең дә алга атлавы дигән сүз.

Фатыйх СИБАГАТУЛЛИН

СЕБЕР КАНАТЫБЫЗНЫ НЫГЫТТЫ

Мәүлидә белән гаилә корып җибәрүебез әле бүген генә кебек. Бактың исә утыз ел гомер үтеп тә киткән икән инде. Өйләнешкәч, авыл клубында бераз эшләп алдык та аннан Себергә юл тоттык. Дөнья күрәсебез килде, тормыш алып бару өчен акчалы булу теләге дә көчле иде.

Улыбыз да Себердә туды, Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» спектаклен дә Татарстаныбыздан шактый ук еракта карадык. Беренче каналдан күрсәттеләр ул спектакльне, Камал театры артистлары уйнаган спектакль, әлбәттә инде, ана телебездә. Күз яшьләренә буыла-буыла, туган төбәгебезне сагына-сагына карадык. Себердә бәхет эзләп килгән татарлар шактый иде.

Рәшидә апа Җиһаншина тудырган Хәмдебану образы барыбызда да соклану уяткан иде. Шул көннән башлап мин хәләл җефетем Мәүлидәгә дә Хәмдебану дип дәшә башладым. Безнең халыкта хәләл җефетләргә күңелләргә хуш килгән исемнәр белән эндәшү киң таралган. Чәчәкләр, җиләк-җимеш исемнәре дисеңме… Миңа калса, бу – бик матур гадәт. Кеше җәмәгатенә ниндидер матур кушамат белән эндәшә икән – бу хуплауга лаек, димәк, хисләр ихлас, мәхәббәт бар.

Читкә китеп, үзеңне сынап карау да кирәк икән – Себер безгә көч-дәрт өстәде, кемнең кемлегенә төшендерде, канатыбызны ныгытты. Татарстаныбызда инде рәхәтләнеп тамыр җәйдек. Нык, бәрәкәтле булды ул тамыр.

Илсур МОРТАЗА,
Татарстанның атказанган артисты

ИМАНЛЫ ГОМЕР

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим.

Узган гасырның туксанынчы елларында, Аллаһының рәхмәте белән, миңа Рафаэль Әмин улы белән танышу мөмкинлеге туды. Халкыбызның дингә, милли үзаңга сусаган чор иде бу.

Шушы елларда без – япь-яшь егетләр, армия хезмәтеннән соң Татарстаныбыз белән чиктәш Ульянның яңа шәһәренә – Идел аръягы районына килеп (бу районны авиатөзүчеләр районы дип тә атыйлар), авиация заводында эшли башладык. Шунда мин милләттәшләребезнең күплегенә шаккаткан идем. Әмма, кызганыч, алар төрледән-төрле иде, берәүләре телен генә түгел, гореф-гадәтләрен дә оныткан, беришләре кирәкмәгән нәрсәләр белән мавыгып, тайгак юлга тайпылып бара. Мине бик нык борчыды бу хәл. Нишләргә? Әлбәттә, мөмкин булганча үзара фикерләшү, җыелып сөйләшү-аңлашу кирәк иде.

Мүкләнгән агачны корт баса, дип юкка гына әйтмиләр. Тулай торакта күршедә яшәүче милләттәшем Зөлфәт Мингалиев белән фикерләшеп, «Яшьлек» клубын оештырып җибәрергә булдык, татар яшьләрен җыя, туплый башладык. Бәхетебезгә, безгә теләктәшлек белдерүчеләр озак көттермәде. Тора-бара район Советы депутаты Рафаэль әфәнде Низаметдинов белән очрашу-танышу насыйп булды, аңа мөрәҗәгать иттек, зарларыбызны сөйләдек. Ул исә милләт, яшьләр язмышы өчен бездән дә ныграк борчылучы булып чыкты, җитмәсә, без якташлар да икән. Ул – Буа районының Иске Тинчәле авылыннан, мин – Тәтеш төбәгеннән. Рафаэльгә Аллаһы Тәгалә буй-сын, чибәрлекне кызганмаган, сөйләме белән дә шундук үзенә җәлеп итә. Ул Идел аръягы районындагы җылылык электр челтәре үзәгендә комсомол оешмасы секретаре да, яшьләр белән эшләүдә азмы-күпме тәҗрибәсе бар. Тора-бара ул – безгә, без аңа таяныч булдык. Рафаэль Низаметдинов Татарстан, Казан белән элемтәләрне ныгытуны максат итеп куйды, чын-чынлап милли һәм дини хәрәкәт башлап җибәрде.

Иң әүвәл чордашларыбызны, яшьләрне җыр-моң белән җәлеп итү максаты куелган иде. Тукай, Җәлилгә, аларның иҗатына багышланган кичәләр оештырдык. Акрынлап, яшьләрне намазга тартып булмасмы икән, дигән фикер дә бөреләнде һәм көткән нәтиҗәне дә бирә башлады. Остазлар табылды, хәзрәтләр ярдәм кулын сузды, алардан гыйлем ала башладык. Шулай да җыелып укырга бер урын кирәк иде, монда инде Рафаэлебез җиң сызганып эшкә тотынды һәм 72 нче мәктәптә бер бүлмә ачу бәхетенә иреште. Гыйлем дә алдык, намаз да укыдык.

Бу инде безгә көч-илһам өстәде, безне аңлаучылар сафы да ишәя барды. Мәчет төзү мәсьәләсе көн тәртибенә куелды. Монда да Рафаэль башлап йөрүчеләрдән булды. Дәүләт, хакимият органнары йогынтысы көчле иде, аның фикере белән исәпләштеләр, аңа ихтирам зур иде. Яңа шәһәрдә хәмерсез Сабантуй оештыруны да ул көн тәртибенә куйды, халыкны туплады, Сабантуйның урынын сайлаганда, бүләкләр әзерләгәндә дә Рафаэльсез булмады. Ул безнең терәгебез дә, башлап йөрүчебез дә иде, беркем белән дә әчелешле булмады, мәсьәләне ыгы-зыгы тудырмыйча, үзара аңлашып хәл итте. Шуның белән милләтебезгә карата ихтирам яулады да. Җитәкчеләр дә мондый эш алымын бик тиз абайлады һәм Ульян төбәгендә милләткә, дингә бәйле баскычларда Рафаэльгә ышаныч күрсәтелде, дустыбыз шул ышанычны тулысынча аклады һәм аклый. Ул милләтебезне, телебезне, тарихыбызны саклау өчен милли хәрәкәтнең дә, диннең дә бердәй дәрәҗәдә мөһимлеген аңлап эш итә. Тырышлык, әлбәттә, бушка китми. Идел аръягы районында мәчет төзелү дә – аның тырышлыгы нәтиҗәсе. Аның Ульян өлкәсе мөфтие урынбасары итеп билгеләнүе дә һич очраклы түгел, дин кардәшләребезне берләштерүдә нәкъ менә аның кебек фидакарьләр кирәк иде.

Яңа шәһәрдә яшәүчеләр аны районның татар автономиясе рәисе итеп сайлап та бары тик отты гына. Ульян белән Казан арасына ышанычлы күпер салучы да ул, Казанга чакыру өчен аңа бер сызгыру җитә, көне-сәгате белән килеп тә җитә, без дә аның үрнәгенә ияреп, күрше төбәккә эзне суытмыйбыз, максатларыбыз бер, теләкләребез изге. Шәһәрнең мәдәният йортында татар театры, балалар иҗат төркеме, мәктәпләрдә татар теле факультативлары эшли, «Ак калфак» эшчәнлеген нык җәелдерде, Ульяновск өлкәсенең һәм Татарстанның атказанган укытучысы Зөһрә Хәбибуллина белән берлектә татар көнкүреше музеен да эшләтеп җибәрделәр.

…Җәлил хәзрәт Фазлыев «Гомер баскычлары» дигән хезмәтендә алты дистәне түгәрәкләп килүчеләрнең яшенә: «Алтмыш яшь – алтын яшь» дигән бәя бирә. Пәйгамбәребез (с.г.в.) «Берәү Аллаһ риза булырлык 60 яшен каршыласа, Аллаһ аны барча күк әһеленнән сөйдерер», – диде. Шөкер, Рафаэль кардәшебез 60 яшен бик матур, игелекле эшләр белән каршылый, гамәл-гыйбадәтләрен үрнәк итеп башкара, киләчәгебез ышанычлы, өметле.

Ильяс ҖИҺАНШИН,
Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге
югары мөселман мәдрәсәсе ректоры

КҮҢЕЛ ЯКТЫСЫ

Адәм баласы пәйгамбәр дә, бер гөнаһсыз фәрештә дә түгел, һәркайсыбызның холкы бар. Хатирә-истәлекләргә бирелеп, журналист, җәмәгать эшлеклесе бертуган апам Әлмира Әдиатуллина хакында сөйләгәндә, аны идеал дип күрсәтүдән бигрәк, гомер юлында очраган, күңелдә онытылмый сакланган вакыйгалар искә төшә.

Бала чагы ачлы-туклы сугыш елларына туры килсә дә, Аллаһы Тәгалә аны саулык белән бүләкләде: нык бәдәнле, сау-сәламәт яшәде. Чордашлары кебек хастаханә юлын таптамады. 83 яшендә дә авызындагы бөтен тешләре үзенеке иде! «Теш сызлау ничек була ул?» – дип сорый иде. Хәер, бер тешен алдырган. Шуннан соң: «Теш куйдырасы бар», – дип йөрде.

Мәктәп елларына килсәк, VII сыйныфны тәмамлагач, апа безнең Сәетколдан 8 чакрым ераклыктагы авылга – тирә-якта тирән белем бирүче, көчле мәктәп булып саналган Дүртөйле районындагы Исмаилга китте. Югыйсә үзебезнең районда да урта мәктәп бар. Әтиебез Лотфулла фронттан гарипләнеп кайтып, өченче төркем инвалид булса да, балаларга бернинди ташлама юк. Укыган өчен елына 150 сум акча түлисе. Ишле гаилә өчен һәм «таяк»ка эшләгән колхозчы өчен бик зур акча бит. Апа район газетасына шигырьләрен, хикәяләрен биргән. «Әлмирага редакция 12 сум, 17 сум акча түләгән» дигән хәбәрләр колакка керә иде. Апаның яхшы укуын ишетә идек. Әмма һаман да шул юклык: әти апаны 9 сыйныфка җибәрмәде. Укырга килмәгәч, сыйныф җитәкчесе белән мәктәп директоры үзләре әти-әни белән сөйләшергә килделәр. «Бик тырыш, сәләтле кыз. Әрәм итәсез, укысын! Юлына киртә булмагыз!» – диделәр. Ә апаны чоланга бикләп куйганнар иде. Аларга күрсәтмәскә, имеш, өйдә юк, дип котылырга. «Мин барыбер Ленин укыган университетка барам, барыбер укыйм», – дип акырып елаулары, өзгәләнүләре әле дә күз алдымда.

Ул елны апа сарык фермасында эшләде. Сарыкларның, бәкәйләрнең исәбе-хисабы юк. Мин дә булышырга йөрим. И-ии, җиренә җиткереп, яратып та эшли иде соң! Тырышлыгын бәяләп, бик матур сарык бүләк иттеләр үзенә.

Уртача тормышта яшәдек. Керосин чамалы бит инде. Әти аны Актаныш дигән җирдән кайтарта.

Бик карап, санап кына тоталар. Апаның ай яктысында китап укуы хәтердә. «Мин укырга тиеш!» – дигән карарында нык торды. Бәрәңге алыр вакыт җитте. Апа Исмаил колхозы басуыннан ике капчык бәрәңге хәстәрләп, Исмаилда яшәп укырга бер апа белән сөйләшеп, кабат укырга китте. Яхшы укыды. «Гел «5ле»гә тәмамласам, ураза тотар идем», – дип нәзер әйткән, һәм бик яхшы билгеләренә генә тәмамлады урта мәктәпне. Шуннан апаның ураза тотуын хәтерлим. Хәле беткәндер инде, эссе көннәрдә күләгәдә утырып торганын беләм. Ул заманнарда кая теләдең, шунда җиңел генә чыгып киттең түгел. Паспорт бирмиләр.

Авылдан чыгып китүе дә көтмәгәндә елмайган язмыш бүләге булды. Районның паспорт бүлекчәсенә матур язучы эзләгәннәр. Хәрефләрне энҗедәй тезә белүчегә генә паспорт тутыруны ышанып тапшыралар иде. Ишкар мәктәбе укытучысы Нурҗиһан апа Шиһапова безнең апаны тәкъдим итә. «Менә 80 паспорт тутыр, берочтан үзеңә дә тутырырсың», – дигәннәр. Апаның шулкадәр бирелеп, шатланып эшкә тотынуы, арып кайтулары, районга йөрүе әле дә күз алдымда.

Ниһаять, ул хыялына иреште, атаклы Казан университетының беренче чыгарылышындагы журналист булды. Шәһәрдән кайткан апага гамьле, фикерлерәк ир-атлар сорауларын әзерләп куялар иде. Алар болынга төшкәнме, ындырда эшлиләрме, апаны сырып алалар, сөйләтәләр. Сорауларын бирәләр. Апа җавап бирә. Кайлардан белеп бетергәндер ул җавапларны, шуңа мин хәзергә кадәр гаҗәпләнәм.

2017 елны апай әнкәй өчен хаҗ кылды. Осиновода яшәүче сеңлебез Зинфираның 65 яшьлек гомер бәйрәменә җыелдык. Апа яңарак кына хаҗ сәфәреннән кайткан иде. Шунда ничек хаҗ кылуы турында сөйләде. Кабыргаларын авырттырып кайткан иде, шактый йончыган, ябыккан.

Әнкәебез Гөлнәзирә зирәк хатын иде. «Әниебез – дөнья бәясе кеше. Их, чак кына уку дигәннәре дә эләккән булса үзенә! Абыйсы урынына Ишкарга мөгаллимә Нәйра апа янына бер баруда хәрефләр өйрәнгән кеше ул. Авылыбызның урак уйнаткан, көлтә бәйләгән, кибән очлаган уңган, эшчән кызы», – дип яза истәлекләрендә Әлмира апа. Әнкәй чисталыкны-пөхтәлекне яратуы белән дә тирә-якта үрнәк булып торды. Тормыш итү өчен хуҗалык кирәк-ярагын булдыруга игътибар итте. Кул тегермәне – ярма яргычыбыз да, үлчәвебез дә, килебез дә, сепараторыбыз да, мунчабыз да бар иде. Тирә-күрше безгә килеп ярма ярдырырга, сөт аертырга дисеңме, мунча ягып керергәме – чират торалар иде. Күпме рәхмәт ишетте ул! Әлмира апабыз да әнигә охшаган: «иншаллаһ», «шулай булырга тиеш» дип тотына иде ул ниятенә. Үз-үзен оныта иде халык белән аралашып, вакыйгалар уртасында булганда. Авылга кайтып керүгә, әле берсенә бара, әле икенчесенә, журналист буларак кызыксына, яза. Үзен аямыйча эшләде, авылдашлар күңелендә генә түгел, райондашлар арасында да хәтергә уелып калды. Гомере буена күңел яктысын салып башкарды безнең апа эш-гамәлләрен. Җыеп әйткәндә, апабыз Әлмира Әдиатуллинаны иҗтимагый тормышта юл ярып баручы буларак та, безнең ишле гаиләбез генә түгел, якташларыбыз да онытмый.

Әлфира ГАТИАТУЛЛИНА-ГАЙСИНА.
Башкортстанның Дүртөйле районы
Карга авылы

Кабырчык – чисталык билгесе

Безнең Ык буйларының торышына күз салсаң, бер кеше гомерендә дә күк белән җир арасындагы үзгәрешләр бу хәлендә дәвам итсә, нәрсә калыр дигән куркуга төшәсең. Малай чакларда хәтердәге күренешләр гүяки төштә генә булган.

Әнә телевизор экраныннан ерактагы бер төбәктә устрица – диңгез моллюскларын җыеп, иң затлы ресторанга тапшыруны күрсәтәләр. Устрица кабырчыгы безнең Стәрле инешенең Ыкка койган тамагында галәмәт дәрәҗәдә тулып ята иде: аны тәмләп пешерү түгел, ашамлыкка яраганын күз алдына да китермәдек. Бу кул киңлеге устрица кабырчыкларын шул Октябрьский, Уфа, Туймазы якларыннан килеп, капчык-капчык төяп китәләр иде. «Моның кабырчыгыннан нәрсә ясыйлар икән?» – дип, без баш вата идек. Сүз уңаеннан, әнә безнең карабодай кабыгын да, бөртегеннән арындыргач кырга, йә чүпкә чыгарып түгәләр иде, ә моны японнар күргәннәр дә үзләренә сатып алып бетерә башлаганнар, тик нәрсәгә тотканнарын сер итеп калдырганнар!

Әлбәттә, устрица кабырчыгы дигәнебез хәзер дә барлыкка килер иде, тик моның өчен чисталык кирәк шул.

Әсгать СӘГЫТДИНОВ.
Азнакай районы

Белдерү

Собрание назначенное на 28.04.2022 года по заявлению Вазетдинова А.А. не состоялось по причине отсутствия кворума.

Повторное собрание, участников общей долевой собственности на земельный участок из земель сельскохозяйственного назначения с кадастровым номером 16:04:000000:243, расположенному по адресу: Актанышский район, на землях СПК «Яхшый», состоится по адресу: Актанышский район, с. Верхнее Яхшеево, ул. Победа, д.59 (здание СДК), 27 июня 2022 г. в 12.00 часов.

На повестке собрания следующие вопросы:

1. Избрание председателя и секретаря собрания.

2. Досрочное прекращение полномочий Бадертдиновой Риммы Фансафовны, действующей от имени участников общей долевой собственности на земельный участок из земель сельскохозяйственного назначения с кадастровым номером 16:04:000000:243, переданному ООО «Эконом» (ИНН 1604007314, ОГРН 1061682044203) по договору аренды № 1 от 20.01.2014 г.

3. Избрание нового представителя участников общей долевой собственности на земельный участок из земель сельскохозяйственного назначенияс кадастровым номером 16 04 00-00-00 0243, переданному ООО «Эконом» (ИНН 1604007314, ОГРН 1061682044203) по договору аренды № 1 от 20.01.2014 г.

4. Досрочное расторжение участниками общей долевой собственности договора аренды № 1 от 20.01.2014 г. в отношении земельного участка из земель сельскохозяйственного назначения с кадастровым номером 16:04:000000:243, заключенного с ООО «Эконом» (ИНН 1604007314, ОГРН 1061682044203).

5. Утверждение проекта межевания земельного участка выделяемого в счет земельной доли из земельного участка с кадастровым номером 16:04:000000:243. Заказчиком работ является Вазетдинов Азгат Азгарович, проживающий по адресу: РТ, Актанышский район, д. Нижнее Яхшеево, ул. Г. Тукая, д.38 (тел.: 8-919-645-12-01).

Проект межевания земельного участка подготовлен кадастровым инженером Аскеровой Еленой Николаевной (квалификационный аттестат №16-15-820, 423603, РТ, Елабужский муниципальный район, г. Елабуга, пр. Нефтяников, д. 44, e.askerowa@gmail.com, 8 (85557) 3-21-11).

С проектом межевания можно ознакомиться в течение 30 дней со дня опубликования данного извещения, а также предоставить в письменном виде (относительно размера и местоположения границ выделяемого в счет земельной доли земельного участка) обоснованные возражения, предложения о доработке ежедневно с понедельника по пятницу с 8 до 17 час. по адресу: РТ, г. Елабуга, пр. Нефтяников, д. 44.

6. Утверждение проекта межевания земельного участка, выделяемого в счет земельной доли из земельного участка с кадастровым номером 16:04:000000:243. Заказчиком работ является Вазетдинов Азгат Азгарович, проживающий по адресу: РТ, Актанышский район, д. Нижнее Яхшеево, ул. Г. Тукая, д. 38 (тел.: 8-919-645-12-01).

Проект межевания земельного участка подготовлен кадастровым инженером, Булатовой Ралией Илшатовной (квалификационный аттестат №16-15-776, 423603, РТ, Елабужский муниципальный район, г. Елабуга, пр.Нефтяников, д. 44, raliya90@mail.ru, 8 9172467786).

С проектом межевания можно ознакомиться в течение 30 дней со дня опубликования данного извещения, а также предоставить в письменном виде (относительно размера и местоположения границ выделяемого в счет земельной доли земельного участка) обоснованные возражения, предложения о доработке ежедневно с понедельника по пятницу с 8 до 17 час. по адресу: РТ, г. Елабуга, пр. Нефтяников, д. 44.

Участнику собрания необходимо иметь при себе: паспорт или иной документ, удостоверяющий личность, а для представителя участника – нотариально заверенную доверенность.

АЭСК

«ООО «Альтернативная энергосбытовая компания» уведомляет, что в соответствии с постановлением Правительства Российской Федерации № 24 от 21.01.2004 «Об утверждении стандартов раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии», на официальном сайте компании http://tataesk.ru/ размещена в полном объеме информация об объеме фактического полезного отпуска электроэнергии и мощности по тарифным группам в разрезе территориальных сетевых организаций по уровням напряжения ООО «Альтернативная энергосбытовая компания».

РӘХМӘТ, АВЫЛДАШЛАР!

Бөтен татар авылларыныкы кебектер инде, «Ватсап»та безнең дә үз төркемебез бар. «Авылдашлар – сөлчәбашлылар» дип атала ул. Сөлчәбаш үзе кечкенә генә, егерме йортлы гына булса да, сиксәнгә якын авылдашым шул социаль төркемдә мәш килә.

Мин бөтен хәбәрне белеп, укып, хәтта карап та барам: клубка мөдир булып каяндыр бер яшь кыз килгән, чүпне район чүплегенә ташучы машина ватылып торган, авыл җирлеге башлыгы янгын куркынычсызлыгы турында кисәтте, иртәгә район үзәгендә гармунчылар конкурсы – рәхим итәбез, түбән очтагы кизләүне чистартырга кирәк… Азык эзләп, урманнан авылга чыгып йөри башлаган кыр кәҗәләрен (косуля) кыш буе ашатып, карап торган авылдашларымның видеоларын Казандагы бөтен танышларыма, дусларыма күрсәтеп, мактанып йөрдем.

Аның, әлбәттә, «хәерле иртә» һәм «Хәрби патриотлар көне белән» кебек, интернеттан алынып, авылны басып алган открыткалары да, чабата буйлык туган көн котлаулары да, тузга язмаган имеш-мимеш хәбәрләре дә, мең тапкыр бер-берсенә күчереп җибәрелгән чүп-чар видеолары да җитәрлек. Ләкин шулай да, минем кебек, авылга кайтып килү җае сирәгрәк эләгә торганнар өчен мәгълүмат чыганагы, почтасы, рухи азыгы, җан сусавын басарлык лирикасы дисеңме – барысына да урын бар анда.

Әле менә беркөн хәбәр салдылар: зиратны җыештырасы иде, кем булдыра – кайтыгыз! Көнен, вакытын билгеләгәннәр: «Елдагыча инде, җәмәгать». «Елдагыча»сы болайрак – йә 1 май, йә 9лары тирәсе. «Ватсап»та хәбәрләшеп, быел майның беренче көненә дип килештек.

Казаннан Сөлчәбашка 200 чакрым чамасы. Ике сәгать ярым арада радиодан авыл турында әллә ничә җыр тыңлап кайттым. Менә бит, мәйтәм, ничек килеп чыга: безнең «Ватсап»тагы төркемдә «авылны яратабыз», «яратам» дигән бер сүз дә юк. Хәтта читтә яшәп ятучылары да «сагындым», «кайтып, шунда каласым килә» дип шыңшымый. Ә менә бүген татар эстрадасын басып алган җырчыларның күбесе «һаман сагына», «мәңге ярата». Аның авылы да атамасыз, туган ягы да абстракт, чишмәсе дә билгесез, таллары-болыннары, урманкырлары коры тал чыбыклары гына бугай, сандугач-тургай тавышларын да алар ишеткәндерме-юктырмы, ай-һай… Менә соңгысының бер куплеты:

Туган якка кайтып киләм,
Кайтыр юлым – полоса.
Үткәннәрем, балачагым
Күз алларыма баса.
Шушы якның, шушы җирнең
Мин – газиз бер баласы.
Шушы якта, шушы җирдә
Килә минем каласым.

Ник, мәйтәм, алай бетеренергә соң? Кайт! Дүрт ягың – дүрт полоса!

Ә менә минем «авылдашлар – сөлчәбашлылар», мәсәлән, зарланып, сагынып тормыйлар. Вакыт юк чөнки. Гомумән, безнең яклар сөю-ярату ише белән нәзекләнеп тормыйлар, сагынып-зарланып мескенләнә дә белмиләр, алай «бәгырьләргә үтәрлек» моңланмыйлар да.

Сөлчәбашның зираты – олы юл буйлап авылга кергән якта. Әле сигез дә тулмаган иде, ә аның койма буенда берничә машина күренде. Мин капка төбенә барып җиткәндә, каберләр арасында байтак кеше мәш килеп эшләп йөри иде инде.

Тагын бер сәгатьтән соң зиратны авылда яшәп ятучы авылдашлар белән бергә Казаннан, Чаллы, Чистай, Түбән Кама, үзебезнең Яңа Чишмәдән кайтучылар «басып алды». Монда беркем дә кушканны көтеп тормый – көрәген, пычкысын, сәнәген, балтасын, буяу-пумаласын ала да баштан ата-анасының, әби-бабасының, үз туганнарының каберләрен җыештыра, чардуганнарын буйый, шул тирәдәге сукмакларда үсеп чыккан куакларны чаба. Аннары, күмәкләшеп, караучысыз калган билгесез каберләрне карыйбыз. Җыелган чүпне капка төбендә торган трактор арбасына ташыйбыз. Аның хуҗасы – 75 яшьлек Камил әзи Ногманов кабинадан егетләрчә сикереп төшә дә, чаба-чаба, ботакларны төяшергә тотына. Аннан да олырак Нәҗия апа Сөләйманова, оныгы белән бергә үзенекеләрнең каберләрен җыештырып бетереп, читтән кайткан якташлар белән күрешеп йөри. Өмәне оештыручы, авылның рухи башлыгы Газизулла хәзрәт Зартдинов балта-пычкыга да, көрәк-сәнәккә дә җитешә. Барысы да гөр килеп, әмма шауламыйча эшли: Ногмановлар һәм Хәертдиновлар токымнары, Сөләймановлар һәм Сатдаровлар нәселләренең вәкилләре, Шәяхмәтовлар һәм Шәрифуллиннар гаиләләре, Зәйнәбетдиновлар, Әхмәдиевләр, Нуретдиновлар, Мохтаровлар, Шәвәлиевләр, Фәрхетдиновлар, Юнысовлар…

Зиратның уртасындагы иске кабер өстендә үскән карт тупылны, җыйнаулашып, бер яктан аркан белән тартып, икенче яктан озын колга белән этеп аударып, турап, капка артына ташып бетергәч, бераз хәлләр-планнар турында сөйләшеп, киңәшеп алдык. Армый да бу халык, талмый да – ун минутлык аягүрә җыелышта бөтен нәрсә турында килештек: Сөлчәбашның – 95, Мәүлет мәчетенең 25 еллыгын Корбан гаете белән бер вакытта бәйрәм итү мәслихәт булыр, дидек. Аңа кадәр урман буендагы мәйданны әзерләргә, авылда яшәгән барлык нәселләр турында альбом-китапны туплап, чыгарып өлгерергә, клубның бер бүлмәсендә музей почмагы оештырырга. «Ватсап»тан белешеп, үземдә азмы-күпме булган мәгълүмат белән бүлешеп торгач беләм: быел Газизулла хәзрәтнең хәер-догасы, киңәшләре, конкрет ярдәме һәм Галия Фәрхетдинова тырышлыгы белән шундый бер бай эчтәлекле, саллы альбом чыкты инде. Ул – мәчетебез турында, авылда динебезне саклап калуга өлеш керткән кешеләр турында. Икенче альбом да уртак хезмәтнең матур нәтиҗәсе булыр, иншалла. Музей да булмаслык хыял түгел, чөнки эшмәкәр Рамил әфәнде Сатдаров матди ярдәм күрсәтеп торырга әзер, ә аның хатыны Рабига «амбар кенәгәләре» кебек документларны үзенең компьютерында цифрлаштыра башлаган да инде.

Менә шул халыкны – «авылдашлар – сөлчәбашлылар»ны бердәмлеккә өндәргә кирәкме? Авылны яратырга өйрәтергәме соң инде аларны?

Узган ел дөнья күргән «Иябәр ни дияр?» дигән китабыма «Безнең авыл ияләре миңа гомер буе ияреп йөриләр» дигән сүзләрне эпиграф итеп куйган идем. Андагы ияләрем – мифик персонажлар. Алар авылның киләчәге өчен борчылалар, кайгыралар, аны саклап калу әмәлен эзлиләр. Ә Сөлчәбаш кешеләре исә – гап-гади кешеләр, әмма чын ияләр, реаль ияләр. Болар борчылмыйлар да, кайгырмыйлар да, «яратам» дип өзгәләнеп җырламыйлар. Авылны тоталар. Бу – чын татар авылы менталитеты!

Рәхмәт сезгә, авылдашларым – сөлчәбашлыларым!

Җәүдәт ЮНЫСОВ.
Казан – Яңа Чишмә – Сөлчәбаш

ТЕРСӘК ЯКЫН ДА, ТЕШЛӘП БУЛМЫЙ

ЯШЬ ПАРНЫҢ АЕРЫМ ЯШӘВЕ ФАҖИГАГӘ ЮЛ АЧА

Суд залыннан

Тормышта шулай да була. Инде бар нәрсә дә җитеш, яшәү-көнкүреш шартлары уңайланды гына дигәндә, кай яктандыр җил-давыл кузгалып, тырышып-тырмашып төзегән уртак бәхетне юкка чыгара. Аннары инде Казанның Портовая урамындагы Фәния һәм Исмәгыйль Нәбиуллиннар сыман үткәнне сагынып яшәргә генә кала.

Әлеге гаилә язмышы белән Казан шәһәренең Вахитов районы суды утырышы барышында танышырга туры килде. Төгәлрәк әйткәндә, суд каршына баскан ир-атның туганы белән кайчандыр газета-журналлар нәшриятында бер чорда эшләгән идек. Мине танып, үзе килеп исәнләште. Газетаны да укып бара икән. Суд бинасында ни өчен йөрүемне аңлатып торасы да булмады. Туганнары турында үзе сөйләде.

…Утызынчы яшь белән баручы Исмәгыйль Нәбиуллин тормышның әчесен-төчесен бала чагыннан ук шактый татыган. Иркутск өлкәсенең Усть-Илим шәһәрендә төзелеш оешмасында эшләүче әтисенең гомере фаҗигале рәвештә өзелгәндә, аңа нибары дүрт яшь була. Әнисе Светлананың япь-яшь килеш тол хатын исемен күтәрәсе килмәгәндер инде, иренең елын да көтеп тормыйча, башка берәүгә кияүгә чыга. Исмәгыйльне исә Казанда яшәүче дәү әтисе белән дәү әнисенә кайтарып куялар. Озакка түгел дисәләр дә, аерылу башта айларга, аннары озак елларга сузыла. Сәбәбе дә гел табылып тора. Баштарак әнисенең бер-бер артлы ике бала табуы, үги әтисенең чит балага кырын карашы да үзенекен иткән, күрәсең.

Хәер, дәү әнисе белән дәү әтисе малайны башкалардан ким-хур итеп үстермәгәннәр. Озак еллар Казан елга портында механик булып эшләгән дәү әтисе Исмәгыйльне үзенең дәвамчысы итеп күрергә хыялланган. Тик, ни кызганыч, Исмәгыйль Казан елга техникумына имтиханнар тапшырып йөргән көннәрдә ул үлеп китә.

Изге күңелле кешеләрнең үзләре мәрхүм булганнан соң да яхшылыгы тия. Исмәгыйль техникумны тәмамлап, эшкә урнашырга дип килгәч, аны дәү әтисенең элеккеге шәкертләре шатланып каршы ала.

Дәү әтисенә ияреп, кечкенәдән Идел елгасында көймәдә йөрүләр, аның серле утрауларында балык шулпасы пешерү, төнге күккә карап, йолдыз күзәтүләр аның күңелендә эзсез үтмәгән, күрәсең. Исмәгыйль җәй көннәрендә, җае чыккан саен, дуслары белән бергәләшеп, Иделнең үзенә бала чактан ук таныш булган утрауларын әйләнеп кайтырга ярата. Шундый сәяхәтләрнең берсендә ул Әлки кызы чибәр Фәнияне очрата.

Яшь чагында тормышта гаҗәеп хәлләр еш була бугай. Әллә шул хәлләр күңеленә тирән җәрәхәт

pixabay.com

салган, әллә инде башка сәбәп белән моңарчы бер генә кызны да күңеленә кертмәгән Исмәгыйль җор телле, чая Фәнияне беренче күрүендә үк үз итә. Шулай булмаганда, очрашуның беренче көнендә үк: «Син минем хатыным булырга теләр идеңме?» – дип сорамас иде. Никадәр кыю булса да, Фәния аптыравыннан өнсез кала. «Алдагыны Алла белә», – дигән җаваптан үзе үк аптырап китә.

Язмыш диген инде. Фәния белән танышуының өченче атнасында, дәү әнисен шаккатырып, кызны кунакка алып кайта. Ә икенче атнада бергәләшеп Базарлы Матакка Фәниянең әти-әнисеннән кыз сорарга сәфәр чыгалар. Кызның әти-әнисе: «Әле бит дүртенче курста гына. Укуын тәмамласын инде», – диюгә дә карамыйча, туй көнен тәгаенлиләр.

Билгеле, яшьләргә бер бүлмәле фатирда яшәү кыенрак булгандыр. Башкалар кебек, бергәләп ял итәселәре, матур итеп киенәселәре дә килгәндер. Тик, болай да очын очка ялгап барган гаиләгә студент кыз да килеп кушылгач, матди кыенлыклар үзен гел сиздереп торган булса кирәк. Өстәвенә дәү әнисенең әледән-әле каты авырып, дарулар алу өчен барлык пенсиясен сарыф итүе дә чүп өстенә чүмәлә сыман өелгәндер. Кыскасы, бергәләшеп яши башлаганның өченче елында Исмәгыйль, илнең иң ерак почмагына барып, диңгездә балык тотып, акча эшли башлый.

Айлар буе аерылышып торуның уңайсыз яклары да булгандыр. Әмма шушы өч-дүрт ел эчендә Исмәгыйль бер бүлмәле фатирын өч бүлмәлегә алыштыра. Өй җиһазлары, затлы кием-салым – кыскасы, тормыш өчен барлык кирәк-яракларны ала. Узган ел исә күптәнге хыялы – берничә миллион сум торучы япон машинасына утыра.

Дәү әнисенең әледән-әле: «Табылмаган мал тау кадәрле. Булганының рәхәтен күрү кирәк», – дип өзелеп-өзелеп әйтүенең артында ни ятканын соңыннан гына аңлый Исмәгыйль. Тормышлары буталмасын дип, килененең башка ир-ат белән чуалуын яшерә дәү әнисе.

Әмма без капчыкта ятмый шул. Соңгы кайтуында «яхшылык теләүче» бер танышы Фәнияне күрше йортта яшәүче Самир Вәгыйзов дигән бер ир-ат белән күргәләве турында әйтә. Кайчандыр бергә дус булып йөргән Самирның чибәр хатын-кызларга чат ябышуын белә Исмәгыйль. Тик хатынының мондый адымга баруына ышанмый.

Ир-ат күңеленә шик керсә, уенда гел шул була бугай. Дөресме икән? Моны ничек ачыкларга? Берничә көннән соң Исмәгыйль, шактый гына салып алгач, Самирның гаражы янында йөрештерә. Берсендә үзен дә туры китерә.

Ачуы, нәфрәте йөзенә чыккан ир-атның ни өчен аның янына килүен Самир бик тиз белеп алган булса кирәк. Гараж эченә кереп, кулына тимер таяк ала.

– Син бит минем дустым идең! Ничек булды бу хәл? Сөйлә!

– Нәрсәсен сөйлим? Ничек булганын хатыныңнан сора!

Кулындагы пычак белән ничә тапкыр селтәнүен дә, Самирның гараждан чыгып чабуын да Исмәгыйль төшендә булган кебек кенә хәтерли.

Судтагы чыгышында: «Максатым үтерү түгел иде», – дисә дә, тикшерү материалларыннан күренгәнчә, Самир Вәгыйзовның төрле җиренә унбиш тапкыр кадаган булуы хак. Шуннан чыгып, Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының «Кеше сәламәтлегенә китерелгән зыянның критерийларын ачыклау турында» 194 нче фәрманы нигезендә «Самир Вәгыйзовның сәламәтлегенә зур зыян салынган» дигән нәтиҗә ясала да инде.

Исмәгыйль Нәбиуллин «ашыгыч ярдәм» машинасын үзе чакыра. Табибларның берничә минут эчендә килеп җитүе, вакытында ярдәм күрсәтелү нәтиҗәсендә Самир Вәгыйзовның гомере саклап калына.

Зыян күрүче үзе дә судтан Исмәгыйль Нәбиуллинга карата каты җәза бирмәүләрен үтенде.

Әмма закон – закон шул инде. Вахитов районы суды Исмәгыйль Нәбиуллинның гаебе тулысынча расланган дип тапты һәм кырыс режимлы төрмәдә тоту шарты белән 9 елга ирегеннән мәхрүм итү турында карар кабул итте.

Камил СӘГЪДӘТШИН

КОТЛЫЙБЫЗ!

Балалар тәрбияләүдәге һәм гаилә традицияләрен ныгытудагы казанышлары өчен Азнакай муниципаль районы буенча Тымытык авылыннан биш бала анасы **Шакирҗанова** Вероника Сергеевна, Арча муниципаль районы буенча Илдус авылыннан җиде бала анасы **Хәбибрахманова** Гөлгенә Шәймулла кызы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге буенча Яңа Савин районыннан алты бала (аларның бишесе өч яшькә җиткән) анасы **Ибраһимова** Миләүшә Нурислам кызы **Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Татар Шуганы авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре **Әхмәдишина** Гөлсинур Шамил кызы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Шумбут авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре **Хәбибуллина** Минзилә Әхәт кызы **«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Республиканың нефть сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директоры каршындагы башкарма аппаратның Татарстан Республикасыннан читтә нефть-газ проектларын эшләү идарәсенең җитештерү проектларын гамәлгә ашыру бүлеге башлыгы урынбасары – проектларны гамәлгә ашыру буенча баш белгече **Кәримов** Наил Варис улы **«Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Полиция полковнигы **Габдерахманов** Ленар Ринат улына **«Татарстан Республикасы буенча атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«ЧАЛЛЫ ИКМӘГЕ» акционерлык җәмгыятенең чималны тарага салмыйча саклау операторы **Имамова** Зинфера Габбас кызына, «Казан май комбинаты» акционерлык җәмгыяте генераль директорының чимал сатып алу мәсьәләләре буенча киңәшчесе **Сыровацкий** Михаил Федоровичка **«Татарстан Республикасының атказанган азык-төлек сәнәгате хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Гадәттән тыш шартларда кешеләрне коткарудагы фидакарьлеге, батырлыгы һәм тәвәккәллеге өчен «Таң» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең авыл хуҗалыгы машиналарын һәм агрегатларын ремонтлау буенча слесаре **Ильясов** Илгиз Зиннур улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Үлемнән коткарган өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Нефть һәм газ сәнәгате өлкәсендәге казанышлары, күп еллар буе намус белән эшләве өчен В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур подразделениесе «Азнакаевскнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсенең нефть һәм газ чыгару буенча операторы **Гәрәев** Марат Мәдхәт улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Машина төзү өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Казан компрессорлы машина төзү заводы» акционерлык җәмгыятенең санлы программалар белән идарә ителешле станоклар операторы **Гәрәев** Рөстәм Равил улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган машина төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Нефть һәм газ сәнәгате өлкәсендәге хезмәтләре, күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Казан моторлар төзү-җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыятенең двигательләр җыючы-слесаре **Абдуллин** Рашат Закир улына; «Казан моторлар төзү-җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыятенең Зеленодольск машина төзү заводы филиалы механик җыю эшләре слесаре **Аникин** Андрей Геннадьевичка; «Казан моторлар төзү-җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыяте токаре **Тотунин** Михаил Васильевичка Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган машина төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Кама-Идел «КВАРТ» резин-техника акционерлык җәмгыяте» акционерлык җәмгыяте хезмәткәрләре: персонал белән эшләү бүлеге башлыгы **Асафьева** Елена Владимировнага, матди-техник тәэминат бүлеге әйдәүче икътисадчысы **Гаязова** Ризида Нурмехәмит кызына, фәнни-техник комплекс башлыгының икътисади мәсьәләләр буенча урынбасары **Гудцова** Наилә Мансур кызына, 115 номерлы цехның үлчәмнәргә бүлү аппаратчысы **Ибраһимов** Әсхәт Мансур улына, продукция китерүне оештыру бүлеге башлыгы **Ключникова** Наилә Максут кызына, баш инженерның хезмәтне саклау һәм сәнәгать куркынычсызлыгы буенча урынбасары – хезмәтне саклау һәм сәнәгать куркынычсызлыгы бүлеге башлыгы **Хәйретдинов** Рөстәм Мөслим улына, 204 номерлы цехның шприц-машина машинисты **Хәсәнҗанов** Илдар Галимхан улына, «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең **«Казан утлары» журналы редакциясе»** филиалы коллективына, Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе оператив планлаштыру, террорчылыкка каршы көрәшү һәм террорчылыктан сакланганлыкны тәэмин итү бүлеге башлыгы, эчке хезмәт подполковнигы **Гыйззәтуллин** Илнур Шаһит улына, Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгы ветераны, Татарстан Республикасы Чаллы янгын сүндерү-коткару гарнизоны Ветераннар советы рәисе, отставкадагы эчке хезмәт полковнигы **Рябов** Анатолий Николаевичка, «Татарстан Республикасы Граждан оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы каршындагы Татарстан Республикасы Эзләү-коткару хезмәте» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесенең 7 номерлы зона эзләү-коткару отряды (Лениногорск) башлыгы урынбасары **Сыраев** Фәсхетдин Хәбетдин улына, Татарстан Республикасы прокуратурасы хокукый статистика, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны саклау идарәсенең ведомство статистикасы бүлеге өлкән прокуроры **Гыйльманов** Ринат Миңнегомәр улына, Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәр прокуроры ярдәмчесе **Мущинина** Вера Ильиничнага, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең мобилизация эше буенча ярдәмчесе **Евстегнеев** Валерий Борисовичка; Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Эшләр идарәчесе **Хәсәнов** Булат Расих улына; **Шәйхетдинов** Рәис Тәбрис улына, «ҖИҢҮ ВОЛОНТЕРЛАРЫ» бөтенроссия иҗтимагый хәрәкәтенең Татарстан төбәк бүлекчәсе рәисе **Идрисов** Азат Альберт улына, Татарстан Республикасы прокуратурасының гомуми һәм махсус эш башкару бүлеге башлыгы **Шәрәпов** Минәкъдәс Әхтәм улына **Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте** белдерелде.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Спас районының «Болгар иле» якташлар җәмгыяте, Иске Рәҗәп авыл җирлеге, ветераннар советы, хезмәт ветераны

Җәмилә Шәмгун кызы МУРАТОВА

озакка сузылган каты авырудан вафат булу сәбәпле, авылдашыбыз, мәрхүмәнең бертуган энесе Камил Сәгъдәтшинның, барлык туганнары, якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА
РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

Бергә җыелганда

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

Сорау – җавап

ҮЗЕМНЕ НИЧЕК ТЫНЫЧ ТОТЫЙМ?

Соңгы арада төшенкелек халәте кичерәм. Шул сәбәпле улыма да тавыш күтәрәм, тиз кызып китәм. Әлбәттә, моны мин уйлап эшләмим, ярсыган чакка туры килә дә, үземне кулда тотып кала алмыйм... Стресс кичергәндә балалар белән элемтәне ничек югалтмаска соң?

Раилә ГАЛИМОВА, 35 яшь

Виктория КОРПАЧЕВА, психолог:
– Монда берничә техника ярдәмгә киләчәк.

Беренчесе – массаж. Ничек кенә сәер яңгыраса да. Кул, баш, арка, аяк... Хәтта чәч! Бала белән элемтәне шул рәвешле югалтмаска гына түгел, ныгытырга да мөмкин. Зуррак балалар белән уртак медитация, йога белән шөгыльләнергә була.

Икенчесе – җырлау. Бала белән булганда көн дәвамында яисә йокларга ятар алдыннан бишек җыры көйләргә мөмкин. Баланың яраткан мультфильмы, фильмыннан берәр герой җырлаган җыр булса, бигрәк тә яхшы.

Өченчесе – бергәләп чәй эчү. Өстәл янында аралашу үзенекен итәр. Аралар да якыная, сөйләшер сүзләр дә табыла.

Дүртенче ысул – уку. Китап, дога, әкият, шигырь, газета – теләсә нәрсә.

Иң үтемле һәм нәтиҗәле ысул – баланы кочаклау, ярату, назлау, иркәләү. Монысын инде бернәрсә дә алмаштыра алмый.

Белеп тор!

БАЛАЛАРГА НӘСЫЙХӘТ

Баһадирлык – адәм балаларында хөрмәтле бер сыйфаттыр. Олылар мәҗлесендә булып, алардан хикмәтле сүзләр ишетү гакылны арттыра вә гыйлемлекне күбәйтәдер. Хәтта кечкенә балаларны бөек адәмнәр мәртәбәсенә якын китерәдер. Шуның өчен, йөрәксез балалар кебек, аталарыгыз сөйләшеп утыруында катнашудан курыкмагыз вә белмәгән, аңламаган нәрсәләрегезне алардан сорагыз, вә һәрнәрсәнең асылын белергә тырышыгыз!..

Урамда йөргән вакытларыгызда атагыз очраса, аңа һәм аның белән берлектә булганнарга сәлам биреп, әмерләрен көтеп торыгыз! Әгәр дә утырып торган вакытыгызда килсә – ачык йөз белән аягүрә торыгыз!..

Бала чагында акча тотарга өйрәнмәгән кеше, олыгайгач та, акча тота белмәс, дөньяда гүзәл көн кичерә алмас, бәлки бар байлыгын исраф итеп, бәхетсез булып калыр. Шуның өчен атагыз тарафыннан бирелгән акчаларны тота белергә өйрәнегез. Сак булыгыз, «Бу – аз акча гына», – дия күрмәгез, чөнки бүген сезнең кирәкләрегез дә бирелгән акча кебек аздыр.

Туганнарыгыз, ата вә аналарыгыз – соңында иң якын кешеләрегездер. Шуның өчен алар белән һәрвакыт әдәпле вә мәрхәмәтле булыгыз! Боларның олыларын ата вә ана урынында санап, итагатьле булыгыз вә сүзләрен тыңлап гамәл итегез! Кечеләренә шәфкатьле булып, аларны бер дә рәнҗетмәгез вә каты күңелле булмагыз. Оятсызлык вә тәрбиясезлектә күчергеч булып, нәрсәләрне тартып алмагыз. Чөнки болай итү аларның каннары бозылуга вә ата-ананы ачуландыруга сәбәп булыр.

(Ризаэддин Фәхреддинның «Әхлак гыйлеме» басмасы файдаланылды)

АЗАЛИЯ ЯФӘСОВА:

«СӘХНӘСЕЗ ЯШИ АЛМЫЙМ»

Чаллыда яшәүче 16 яшьлек Азалия ЯФӘСОВА, сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән булса да, тормыш авырлыкларына бирешми, үз хыялына таба бара. Моңлы тавышы һәм тырышлыгы нәтиҗәсендә күп кенә дөнья, ил һәм республика күләмендә фестивальләрдә җиңү яулый ул. Яшь талант иясе белән җыр һәм хыяллар турында сөйләштек.

:: Азалия, җырлы-сәхнәле тормышың ничек башланды?
– Мин 3 яшьтән җырлый башлаганмын. Кечкенә чагымда дәү әнием миңа татар һәм башкорт халык җырларын көйләгән. Аларны тыңлап, йокыга китә торган булганмын. Башта мин Чаллының шәһәр балалар һәм яшьләр иҗаты сараенда өч ел укыдым. Аннан соң җиденче музыка мәктәбенә йөри башладым. Сигезенче ел шунда шөгыльләнәм. Быел соңгы елым, май ахырында имтиханнар көтә.

:: Син – «Йолдызлык», «Добрая волна», «Белая трость» кебек халыкара, илкүләм һәм республика күләмендәге фестивальләр лауреаты. Конкурсларда үзең теләп катнашасыңмы?
– Төрле конкурсларда теләп катнашам, чөнки миңа сәхнәдә булу бик ошый. Мин, гомумән, сәхнәсез яши алмыйм. Иҗат кешесе буларак, гел сәхнәгә тартылам. Төрле җырчылар белән чыгыш ясарга, дуэтлар җырларга бик яратам. 2020 елда «Белая трость» халыкара хәйрия фестивалендә җиңү яулап, Россиянең һәм Татарстанның атказанган артисты Алсу белән дуэт җырладым. Әлеге проектны Россиянең атказанган артисты Диана Гурцкая оештыра. Фестивальдән соң безне Мәскәүгә кунакка да чакырды әле ул. Быел икенче тапкыр «Балалар премиясе» проектында катнашып, Ильмира Нәгыймова белән чыгыш ясадым.

:: Нинди җырлар башкарырга яратасың?
– Мин күбрәк татар җырларын җырларга яратам. Халык җырларын да, эстрада стилендәгеләрен дә үз итәм. Рус телендә дә җырлыйм, тик татар халык мелизматикасы белән җырлаганга, минем тавыш күбрәк татар җырларына туры килә. Нәркис

абый Зиннәтуллин белән «Яратам, сагынам» һәм «Әни назлары» дигән ике җыр яздырдык. Безнең дуэтыбызны ошаттылар. Мин моңа бик шатландым.

:: Киләчәктә үзеңне җырчы итеп күрәсеңме?
– Әйе, үземне киләчәктә җырчы итеп күрәм. Тагын да зур үрләрне яуларга, танылган артистлар белән җырларга, татар эстрадасына кереп китәргә телим. Эстрадада көнчелек дигән әйбер дә бар, билгеле. Тик мин моннан курыкмыйм, үзеңнең сайлаган юлыңа тугры булырга кирәк.

Кунагыбыз турында белешмә

✓ Азалиягә – 16 яшь;
✓ Чаллының мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен 75 нче мәктәбендә 8 нче сыйныфта белем ала;
✓ өч яшеннән җырлый, клипларда төшә, бөтенроссия һәм халыкара фестивальләрдә катнаша;
✓ җырчы булырга хыяллана.

:: Яраткан җырчың бармы?
– Филүс абый Каһировның җырларын бик яратып тыңлыйм. Үзе белән «Балалар премиясе»ндә беренче тапкыр катнашканда дуэт та җырлаган идек. Шулай ук, Ришат Төхвәтуллин, Зәйнәб Фәрхетдинова, Гүзәл Уразова, Ильмира Нәгыймова, Ришат Фазлыйәхмәтов иҗатларын яратам. Санап китсәң, бик күп инде алар.

:: Җырлаудан тыш тагынниләр белән шөгыльләнәсең?
– Җырларымны, көйләрне нотага салып, фортепианода, синтезаторда уйнарга тырышам. Моның үземә киләчәктә кирәге чыгар дип уйлыйм.

:: Ничек уйлыйсың, үзеңдә сәләтне ачу өчен нәрсә эшләргә кирәк?
– Үзеңдә сәләтне ачу өчен бик нык тырышлык һәм кыюлык кирәк. Кешедә бу сыйфатлар булмаса, ул үзенең сәләтен ача алмаячак. Һәрвакытта да алга барырга, үз өстеңдә эшләргә, абынсаң да, башны горур күтәреп: «Мин булдырам!» – дип яшәргә кирәк.

:: Бүген син нәрсә турында хыялланасың?
– Җырлавым белән кешеләрне сөендерергә, зур сәхнәләрдә балкырга хыялланам. Шулай ук дөньядагы барлык кешеләрнең сәламәт булуын телим.

Әңгәмәдәш – Ләйсән САФИНА

САБАК

Бәләкәй чакта кем генә үчекләшергә яратмады икән? Миндә бу сәләт бигрәк нык үскән иде. Берәр кешенең җитешсезлеген күреп, шунда ук такмак чыгара идем.

Кешегә кушамат тагу, үчекләү башлангыч сыйныфларда үзе бер «мода» булды. Әгәр чәче бөдрә икән – сарык, үчекләшеп телен күрсәтә икән – маймыл, буйга озынрак булса – жираф, танавы зуррак күренсә – торна... Үземнең дә кушаматым бар иде, анысын әйтеп тормыйм.

Бервакыт шигырь язарга булдым. Сыйныфташларымның һәрберсен ниндидер җәнлек белән чагыштырып. Үзем язам, үзем көләм. Шигырь ярыйсы ук уңышлы килеп чыккандай тоелды. Әйтерсең лә сыйныф – тоташ зоопарк. Шуннан эчтән генә уйлыйм: әгәр яшьтәшләрем бу нәрсәне укыса, тетмәмне тетәчәк бит! Бүтән берәү дә күрмәсен дип, кәгазьне йомарладым да чүп кәрзиненә ташладым. Олы бәладән котылгандай, өйгә кайтып киттем.

Иртәгәсе көнне сыйныфка килеп керү белән, барысы да гү итеп алды. Укытучы мине алга чыгарып бастырды, сыйныф старостасы теге шигырьне кычкырып укырга тотынды! Барысы да мине тишәрдәй итеп карый, малайлар ташланырга әзер тора. Ә мин гарьлегемнән җир тишегенә кереп китәрдәй булдым.

Безнең белән бергә укыган кызның әнисе мәктәптә җыештыручы булып эшли иде. Шул көнне сыйныфташыбыз әнисенә ярдәмләшергә килгән. Күрәсең, ул кабинетта торган чүп кәрзинендә чокынганда, теге шигырьгә юлыккан. Иртәгәсен үк аны укытучының кулына тоттырган...



pixabay.com

Моннан соң башка беркайчан да язу белән булышмыйм дип үземә ант иттем. Кешеләрне үчекләмим дип тә сүз бирдем. Үчекләшү гадәтеннән котылдым шикелле, тик тәүге антымда тормадым. Язмый булдыра алмадым...

Айгиз БАЙМӨХӘММӘТОВ

Абый күзләре

Тәрәз рамнарының эчләрендә
Алтын яфрак кабат әйләнә.
Укытучы абый! Җитди караш!
Ә мин – җүләр, телем бәйләнә!

Тилмереп, ул түзем генә көтә,
Туган телдә бер сүз әйткәнем.
Ә мин кабат «табиб» диеп түгел,
Горур гына «врач» дип әйткәнмен.

«Сәлам!» урынына «привет!» димен,
«Как дела?» да шуңа ялгана.
Сөйләмемдә рус сүзләре үрчи,
Бер-бер артлы чүпләп ал гына!

Җаныбызны дәваларга теләп,
Абый чүпләп-чүпләп карый да,
Күзләренә бер моңсулык иңә,
Аны чүпли-чүпли арый да.

...Абый никтер тагын моңсу бүген.
Минем телем тагын бәйләнә!
Сары яфрак тәрәзәдә түгел,
Абый күзләрендә әйләнә.

Йосыф ШӘҢГӘРӘЕВ.
Казан шәһәре

Бергәләп әзерлибез!

Круассан

Кирәк булыр: 0,5 литр кефир, 200 г атланмай, 1 йомырка, 1 чәй кашыгы тоз, 1 чәй кашыгы коры чүпрә, 1 аш кашыгы шикәр комы, 4 стакан он, 1/3 стакан үсемлек мае.

Эш барышы: чүпрәне җылытылган кефир, тоз, шикәр комы белән болгатып, берничә минут тотабыз. Атланмайны эретеп, йомырка сытып туглыйбыз, чүпрә кушылган кефирны, он, үсемлек мае кушып, камыр басабыз. Аны целлофан пакетка төреп, 1 сәгатькә суыткычка куеп торабыз.

Аннан камырны җәеп, өчпочмаклап кисәбез, һәркайсының киң ягына эчлек (ул сез яраткан җиләк-җимеш, кайнатма, куертылган сөт, мармелад, шоколад та була ала) куеп, круассан рәвешенә китереп төрәбез. Йомырка сарысы белән майлап, 180 градуска кадәр җылытылган газ мичендә пешерәбез. Табынга биргәндә өстенә шикәр пудрасы сибәргә мөмкин.

Гаҗәеп дөнья

✓ Безнең планета, нигездә, тимер, кремний һәм аз күләмдә магнийдан тора.
✓ Сигезаякларның – өч, ә суалчаннарның биш йөрәге бар.
✓ Дөньядагы иң биек агачның буе – 115,61 метр. Ул Калифорниядә үсә.
✓ Зәңгәр китның йөрәгенә бер җиңел машина сыя ала.
✓ Японияда куяннар гына яши торган утрау бар.
✓ Португалиядә кызыл төс кулланып язарга ярамый.
✓ Тәвә кошының күзе аның баш миенә караганда зуррак.

ФАЙДАЛЫ ГАДӘТЛӘР

	дүш	сиш	чәрш	пәнҗ	җом	шим	якш
Урын-җирне җыештыру	○	○	○	○	○	○	○
Савыт-саба юу	○	○	○	○	○	○	○
Малларны карау	○	○	○	○	○	○	○
Гөлләргә су сибү	○	○	○	○	○	○	○
Киемнәрне таслап кую	○	○	○	○	○	○	○
Бүлмәне җыештыру	○	○	○	○	○	○	○

Әлеге белешмәлек сиңа атна дәвамында файдалы гадәтләр булдырырга ярдәм итәчәк. Кисеп ал һәм үтә.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 7061 данә
Гомуми тираж – 16033 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 266

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+